# Служил он людям всей душой

Книга посвящена творчеству
Мунавира Фазлыева

*Книга посвящена творчеству*
*Мунавира Ибрагимовича Фазлыева,*

*поэта и прозаика, отличника народного просвещения Российской Федерации.*



*7 апреля 1934 г. – 19 июля 2014 г.*

# Служил он людям всей душой

Это книга воспоминаний и личных впечатлений, переживаний ветерана педагогического труда М. И. Фазлыева, которому в 2019 году исполнилось бы 85 лет, сорок лет жизни из которых он посвятил воспитанию молодого поколения.

В книге собраны публицистические заметки, очерки, эссе, напечатанные в республиканских, янаульских районных газетах, журналах, написанные в разных жанрах. Ее страницы повествуют о рядовых тружениках: о первых механизаторах, агрономах, хлебопашцах села Истяк, о председателях колхоза им. М. Горького, которые свою трудовую биографию посвятили развитию экономики, животноводства нашего колхоза и района. Читатели узнают много интересного о трудолюбивых, дружных семьях односельчан, о передовых учителях нашей Истякской средней школы.

Его никогда не покидала мечта написать книгу об истории своей деревни Истяк, о замечательных односельчанах, успехам которых он искренне радовался, от всей души желал им веры в свои силы, добрых перемен в их жизни.

Выпуская эту небольшую книгу, я считаю своим долгом, обязанностью довести до конца его мечту, чтобы внуки и правнуки Мунавира Ибрагимовича помнили его и гордились им. Он этого достоин.

***Рашида ФАЗЛЫЕВА,***
***супруга Мунавира Ибрагимовича.***



# Үзем хакында сүзем

1934 елның 7 апрелендә Яңавыл районының Истәк авылында туганмын. Яңавылда урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияте бүлегендә югары белем алдым. Диплом эшем «Шәйхзадә Бабичның иҗатында юмор һәм сатира» дигән тема иде. Ш. Бабичның әсәрләрен күпсанлы архив материалларыннан җыеп, туплап, аңлатмалар биреп, 1958 елда Казанда бастырып чыгардык. Филология фәннәре докторы, профессор, кафедра мөдире Хатип ага Госман бу юнәлештә зур эш башкарды, җыентыкка эчтәлекле кереш сүзне дә ул язды. Бу китапның әһәмиятен аңлатып торуның кирәге юктыр, мөгаен. Тик шуны әйтәсе килә: Ш. Бабичның әсәрләре утыз алты ел буена китап булып басылып чыкмаган, халык бу зур әдипнең әсәрләрен укудан һәм өйрәнүдән мәхрүм ителгән иде.

Кечкенәдән әдәбиятне, театрны яраттым. Үзешчән сәхнәдә концерт, спектакльләрдә катнаштым. Башлангыч сыйныфларда ук шигырь яза идем. Моның сәбәбе бик җитди: Газимә һәм Нәгыймә апам хат ташучы булып эшләде. Алар алып кайткан газит-журналлар белән укып-таныша һәм кайбер әсәрләрне ятлый торган идем.

Аеруча әти-әнигә рәхмәтлемен. Алар сәнгатьне сөйде һәм безне дә гүзәллеккә җәлеп итәргә тырышты. Алардан «Сак-Сок» бәетен, «Ахырзаман», «Мәүлит» һәм башка халык әсәрләрен тыңлап үстем. Әни укырга, язарга белә иде. Туксан өч яшендә, вафатыннан берничә көн алда, «Картлык көннәре» дигән мөнәҗәтен ишеттерде.

Хәләл җефетем Рәшидә Закирҗан кызы белән бер үк уку йортын тәмамлап, һәрвакыт бергә-бергә тормыш һәм сәнгать юлыннан атлыйбыз. Туганнарым, балаларым җыр-биюгә, әдәбияткә мөкиббән гашыйк.

Шигырьләрем район, «Кызыл таң», «Өмет», «Татарстан

яшьләре», «Шәһри Казан» һәм балалар гәзитләрендә, «Башкортостан укытыусыһы» журналында дөнья күрде. 2000 елда Казанда «Агым сулар» дигән китабым чыкты, шигырьләр шәлкемем Башкортстан «Китап» нәшриятендә «Акчарлак» альманахында басылды, 2003 елда шушы нәшриятта балалар өчен шигырьләрем «Колыннар, колынкайлар» дигән аерым җыентык булып нәшер ителде.

Берничә шигырьгә үзешчән композиторлар көй язды. В. Хәбисламовның «Тепловоз» дигән шигыремә язган көе иң озын гомерлесе булды. Сәнгать мәктәбе укытучысы Г. Зыязова, Ямады мәктәбе укытучысы Р.Исламов, Истәк мәктәбен тәмамлаган укучым М.Вәҗетдинов та шигырьләремә көй иҗат итте.

Университетта укыган чордан гәзитләргә языштым. Район гәзитендәге берничә айны исәпләмәгәндә, гомеремне мәгарифкә багышладым, тел һәм әдәбият, тарих укыттым. Истәк мәктәбе директоры йөген тарттым. Русия Федерациясенен халык мәгарифе алдынгысы исеменә лаек булдым.

Хезмәт эшчәнлегемнең биш елында (1990-1995) Истәк авыл Советын җитәкләдем. 2000 елдан лаеклы ялда, туган авылымда яшим.

***Мөнәвир ФАЗЛЫЕВ.***

# Истәгем

*Балкып тора туган авылым,*
*Ни җитә Истәгемә.*
*Сөйкемле (акыллы) авылдашларым*
*Һәрвакыт истә генә.*

*Яратам мин гүзәл Истәгемне,*
*Әнкәм кебек бердәнберемне.*
*Әтиләрдән мирас булып калган*
*Бәрәкәтле изге җиремне.*



# Сагынам сине, әнкәй

*Рәсемеңә озак карап торам,*
*Актарганда альбом битләрен.*
*Ишетәсеңме, әнкәй, сызлап-сагынып,*
*Йөрәгемнең ярсып типкәнен?*
*Белмим, нигә озын керфекләрем*
*Кайнар яшьләремә манчыла?*
*Альбом битләренә тып-тып тама*
*Күзләремнән аккан тамчылар.*
*Күкрәгемә сыймый, сагышланып,*
*Дулкыннардай дулый хисләрем.*
*Нигә безне кинәт ятим иттең,*
*Нишләдең син, әнкәй, нишләдең?*
*Яшәдең син тормыш кадерен белеп,*
*Яңа көн туганга куанып.*
*Сары сагышларны басар өчен*
*Рәсемең дә ярап куя бит.*
*Язлар саен шаулап чәчәк ата*
*Син үстергән иркә гөлләрең.*
*Татлы төшләр генә булган икән*
*Бергә дөнья көткән көннәрем.*

# Нигә, әткәй, моңландың

*Иртәнге талгын, саф һава,*
*Ат лырт-лырт юртып бара.*
*Якынлашып килә урман,*
*Үткәнбез шактый ара.*

*Әтием тик болай гына:*
*– Әйдә, малкай! – дип куя.*
*Каккалый ак дилбегәсен,*
*Янәсе, атны куа.*

*– Өшемәдеңме, улым? – дип*
*Сораштырып алгалый.*
*– Тирә-ягыңны карап бар,*
*Күзең йомып калма, – ди.*

*Җылыта каплап битемне*
*Җылы куллары белән.*
*Туңсам әгәр, күлмәген дә*
*Салып бирәсен беләм.*

*Чана астыннан сузылып,*
*Ялтырый ике тасма.*
*Авылым күздән югалды,*
*Төшәбез үрдән аска.*

*– На, малкай! – дип кабатлады,*
*Тарткалап дилбегәсен.*
*Күңелең ник нечкәргәнен*
*Килә минем беләсем.*

*Җырлап җибәрде әтием,*
*Юлда күңел үсәдер:*
*– Һаваларда йолдыз, ай, ничәдер,*
*Санаган саен күчәдер...*

*Нигә, әткәй, карлы юлда*
*Таң атканда җырладың?*
*Җырыңның соңгы сүзләрен*
*Ишеттерми, тын калдың?*

*...Таңнарда йөрим урманда,*
*Ишетеп тавышыңны.*
*Әллә шуңа бәйләдемме*
*Моңга үз язмышымны?*

# Күңел дәфтәреннән

Студент елларында һәм хәзер дә мина дусларым, якын итеп, үз итеп «Фазлый» дип эндәшә. Дус-ишләремнең шулай мөрәҗәгать итүе күңелгә ниндидер җиңеллек, үзем дә аңлап бетермәгән рәхәтлек бирә торган иде.

Әйе, мин – Фазлыйәхмәт улы Ибраһимның төпчек улымын. Русчалабрак әйткәндә, Фазлыев Мөнәвир Ибраһим улымын, төпчек улымын. 1934 елның 7 апрелендә Башкорстанның Яңавыл районы Истәк авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килгәнмен. Гаиләбездә алты бала булып, шуларның дүртесе бүген дә исән-сау, балаларының ярдәме һәм үзләре дә аларга күрсәтә алган ярдәменә канәгать булып, рәхмәтләр укып яшиләр, иншалла.

Истәк башлангыч, Иске Көек җидееллык, Яңавыл беренче санлы урта мәктәпләрен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып югары белем алдым. Дипломым буенча һөнәрем татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филолог. Татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары башка бүлекләрдә укытыла торган барлык фәннәрне үзләштерә, курс эшләре яза, зачетлар бирә, имтиханнар тапшыра, өстәмә рәвештә үзләренең бүлегенә хас предметларны үзләштерә.

Үземә калганда, яхшы гына укуымны тәмамлап, үзебезнең Яңавыл районына кайттым. Район житәкчелеге район гәзитенең хатлар бүлеге мөдире итеп тәгаенләде. КПССның район комитеты мине шул эшкә раслап куйды.

Журналист булып эшләрмен дигән теләгемә карап тормадылар, райком бюросына чакыртып, Истәк җидееллык мәктәп директоры итеп тәгаенләп, туган авылыма кайтарып җибәрделәр. Кунакка түгел, эшкә, әлбәттә.

Мин кайтканда мәктәп дүрт бинада урнашкан, аралары ерак кына иде. Аеруча, калай түбә һәм элекке медпункт йортлары укытучылар бүлмәсеннән 50-80 метр ераклыкта урнашкан. Кышкы салкыннар һәм бураннарда, өсләренә ничек кирәк шулай каплаштырып, кыңгырау шылтырау белән шул йортларга йөгерәләр, үзләренә салкын

тиеп бетә, дәрес сәгатьләре 5-10 минутка кыскара. Төп бина – элекке мәчет. Ике катлы итеп эшләнгән. Аңа терәп өч бүлмәле бер катлы йорт салынган. Шуның бер бүлмәсе укытучыларныкы. Анда төрле киңәшмәләр үтә, расписание, сыйныф журналлары, методик журналлар һ.б. тупланган. Җыештыручы апалар, иртәнге сәгать дүрттә килеп, мәктәпне утын белән (11 мич) җылыта. Мәчетнең икенче катына кочак тутырып утын, көянтәләп су мендерүләре ничек авыр иде! Юк кына хезмәт хакына хәзерге яшьләр түзеп эшләр идеме икән? Ул чакларда эшлиләр иде. Укучылар килгәнче, мичне томалап, күмер исен бетереп, җыештырып, мәктәпкә шактый ерак чишмәдән көянтәләп су ташып, титанда су кайнаталар. Мәктәп ике сменада, кичке мәктәп белән өч сменада эшләде. Өстәвенә, җыештыручылар мәктәптә чиратлап дежур тора, кыңгырау шылтырата, укучыларның тәртибен күзәтә. Җилле көннәрдә мәктәп суына, укучылар киенеп утырып дәрес тыңлый, яза, рәсем төшерә, мәсьәлә чишә. Көчле җил булганда, мәчет, ыңгырашкандай, вакытвакыт шыгырдап куя. Балаларның кайберсе куркып сискәнеп китә, дәресләр дәвам итә.

Кайтып эшкә башлаган көннәрдә мәктәпнең завучы булып Иске Көек җидееллык мәктәбендә физика, математика, химия фәннәреннән безне укыткан Салихов Барый Саматович эшли иде. Ул японнар белән сугышкан, дингезче, акыллы, артык тырыш, тумышыннан ук талантлы педагог иде. Авыл һәм район җәмәгатьчелеге арасында тирән абруй казанып өлгергән иде. Мәктәп директоры да, завучы да, роно инспекторы да булып эшләп, бай тәҗрибә туплаган, гаҗәп тыйнак, тотнаклы, сабыр, кешелекле һәм кечелекле, туры сүзле, киң эрудицияле һөнәрман шәхес иде. Барый Самат улын, хөрмәтле укытучымны, халыкта «хәрәкәттәге энциклопедия» дип атап йөртәләр иде. Киң эрудицияле, гадел, таләпчән булганы өчен укучылар да, укытучылар да, ата-аналар да Барый абыйны бик ярата идек. Аның дәресләрендә дөрес җавап бирмәгән очракта «Дуга белән печән чапма» дип кистереп әйтеп куя торган иде.

Барый абый коллективны туплауга, аның нәтиҗәле, иҗади эшләвенә, педагогика өлкәсендәге яңалыкларны өйрәнүенә үзенең таләпчәнлеге белән ирешә иде. Ул озак еллар башлангыч сыйныф укытучыларының методик оешмасына җитәкчелек итте, балалар-

ның белемле, тәрбияле булуына үзенең зур өлешен кертте. Бернинди дә физик эштән тартынмады. Урыны җәннәттә булсын.

Казанда укып кайткан дәртле яшь кешегә Барый Самат улы кебек таянычың, киңәшчең, остазың булу – зур бәхет бит ул, туганнар!

Барый абый белән киңәшләшеп, мин яңа мәктәп төзү, район планына кертү, рөхсәт алу өчен район оешмаларына барып йөри башладым. Андый рөхсәтне бер ел эчендә генә ала алмадым. Ул елларда мәктәп, мәдәният объектларын төзү алгы планда тормый иде. Төп игътибар терлек тораклары төзүгә юнәлтелгән иде.

Район Советы рәисе Әлфәт Мәккән улы Усманов хәлне аңлап, Истәк авылында типовой мәктәп салырга дигән карар кабул итте. Ленинградтан проект кайтарттык, Уфада проект-смета документларын тиз генә эшләп бирделәр.

Чирек гасырга якын мәктәп директоры булып эшләү дәверендә хуҗалык ысулы белән районда беренче булып таштан 320 урынлык типовой мәктәп (спорт залы, лабораторияләре, китапханәсе, тегү остаханәсе һ.б. ярдәмче бүлмәләре белән) төзеп куйдык. Мин, нинди могҗиза булгандыр, җиденче сыйныфта укыганда, сызым дәресендә нәкъ шундый мәктәп рәсеме эшләгәнмен. Озак сайладым ул рәсемне. Әле төзелгән мәктәп бинасын «кече университет» дип атап йөрттем, эчтәлеге белән дә, формасы белән дә университет бинасына охшатырга тырыштым. Казан университетының бинасы да П формасында, безнең мәктәпнеке дә шундый булсын, янәсе.

Мин эшкә башлаган 1958 елда мәктәптә күпчелек укытучылар педучилище һәм ун сыйныф белеме белән укыта, югары белемле укытучылар дүртәү генә иде.

Мәктәпнең кечкенә агач будкасында электр двигателе бар. Математика укытучысы мәрхүм Суфиян агай Галимов шул двигательне кабызып җибәрә, лампочкалар кабына, бүлмәләр яктыра, рәхәт. Тик озакка түгел шул, күпчелек очракта җиделе, унлы һәм ике утызлы керосин лампасы яндырабыз.

Җыештыручылар Фазыйла апа Нәсибуллина, Маһия апа Әхтәмова, Нәгыймә апа Исламгалиевалар, алар пенсиягә киткәч, Мөкәррәмә Шакирова, Газимә Харисова, Наһар Имәметдинова, Наилә Фазлыева апалар ягулык сезоны башлангач, иртәнге сәгать дүрттә килеп, бүлмәләрне җылыту өчен мичләргә ягалар. Унбер

мич. Балалар укырга килгәнче мичне томалап, җыештырып кайтып китәләр. Кайчакларда утын чи, балалар укуга килгәндә мичләр томаланса да, бүлмәләр җылынып өлгерми, мичтә янып бетмәгән кәүсәләрдән-кисәү башларыннан ис чыга, каралар туна.

Кышкы салкын, көчле җилләрдә ике катлы мәчет (анда дүрт сыйныф укый иде) куркыныч шыгырдап, күңелгә шом сала. Хәзер уйлыйм: ничек итеп кочак-кочак утын күтәреп, су күтәреп менгәннәрдер җыештыручы апалар. Кичке карангыда биек текә баскычтан тәгәрәп төшкән чаклары да булды аларның, Ходай саклады, имгәнүчеләр булмады.

Җәй буена ал белми, ял дими кул пычкысы белән җыештыручылар утын кисә, яра, киптереп такта складка әрдәнәгә өя. Мәктәп ишек алды пристаньне хәтерләтә иде. Әле дә уйлап кызганып куям җыештыручы апаларны, ничек түзде икән арка, беләкләре. Тагын кышкы ягулык сезоны башлана. Коры каен утыны бүлмәләрне җылыта, балаларга чишенеп утыру мөмкинчелеге дә туа.

Мәктәп бер-берсеннән шактый ерак арада утырган дүрт өйдә урнашкан. Мәчеттә дүрт сыйныф, аңа өч бүлмәле өй терәп эшләнгән. Шуның берсе укытучылар бүлмәсе, икесендә укыйлар. «Калай түбә»дә (1914 елда салынган Габдрахман Мозаффаровның бай



***«Калай түбә» (1914 елда салынган Габдрахман Мозаффаровның бай йорто). 1960-нчы еллар.***

йорты) бер бүлмә – хезмәт остаханәсе һәм спорт залы ролен үти. Көньяктагысы – сыйныф бүлмәсе. Укытучыларга ун минутлык тәнәфестә дәрес саен бер өйдән икенче, өченче өйгә, пальтоларын аркаларына салып, вакытында барып житәргә кирәк.

Шулай итеп, мәктәптәге эш һәм яшәү шартлары белән танышканнан соң, яшь директор алдына катлаулы бурычлар килеп баса:

1. Мәктәпне тиешле кадрлар белән тәэмин итү, ир укытучыларны җәлеп итү.

2. Мохтажларга фатир салып бирергә.

3. Яна Көек, Чулпан, Сабанчы авылларыннан йөрүче укучыларга интернат төзергә.

4. Укыту-тәрбия эшләренең сыйфатын күтәрү өчен, укучылар һәм укытучыларның эш шартларын тамырыннан үзгәртергә. Моның өчен яңа мәктәп бинасы төзергә.

5. Укучыларны да, укытучыларны да кайнар аш белән тәэмин итәргә.

Мин төзеләсе мәктәпне «кечкенә университет» дип атадым. Булса шундый булсын ул мәктәп, анда сыйныфлардан тыш, гимнастика залы, китапханә бүлмәсе, хезмәт остаханәсе, төрле кабинетлар, ярдәмче бүлмәләр... Дүрт-биш укучы утыра торган иске парталарны заманча мебельләр белән алыштырырга, техник чаралар, күгәзмә әсбапларны яңартырга һ.б. Мич ягып түгел, мәктәп үзәк ягулык системасыннан җылынырга тиеш.

Кечкенә университет якты да, иркен дә, җылы да булсын.

Яхшы, мәктәпнең кечкенә булса да, аты да булды. Аңа зур булмаган абзар да салып куйдык. Мәктәпнең коесы юк, суны еractан ташып, җыештыручы апаларның аркалары чиләнеп бетә. Кое казып куйдык.

Мәктәп фатиры (өч бүлмә, интернат, ике бүлмә) салынды. Сап-сары нарат агачыннан салынган интернатта укучылар яши башлады, ләкин ул мичкә ягып җылытыла, шулай да яшәргә мөмкин.

Роно, райсовет, райком юлларын таптый торгач, мәктәп төзү мәсьәләсе дә унай хәл ителде. Мәктәп төзү өчен кирәкле материалларны җыю җиңелдән булмады. Мәктәп төзелергә тиешле урынны озак кына сайладык.

Ул елларда колхоз рәисе булып эшләгән Кәрамхан Шәймора-

тов мәктәпне хәзерге терлекчелек комлексы, ягъни ферма янына төзергә тәкъдим итте. Ул үзенең тәкъдимен колхозда терлекче һөнәренә кытлык булуы, савучылар һәм терлекчеләр, галим зоотехникларның бөтенләй булмавын мәктәпнең терлек фермасы белән ныклы бәйләнештә эшләмәвеннән килә дигәнрәк фикерен әйтте. Авылдан мәктәп салыначак урын ярты километр чамасы ераклыкта. Укучыларны автобус белән йөртербез, диде ул.

Авыл Советы рәисе – халык абруен казанган Фәхрай Фәттахов мәктәпне Ахтиял белән Истәк авыллары уртасына салырга кирәк, дигән фикерен әйтте. Каймаша елгасы буендагы Бәнибаш, Ахтиял, Истәк, шулай ук Сабанчы балаларына ераклык бер чамарак булыр иде.

Кәрамхан абый бик көчле җитәкче, күренеп торса, тартып алыр, диләр андый кешеләрне. Мине яшь, тәҗрибәсез, моны «бөгәргә» була дип уйлап, мәктәпкә бүленгән төзелеш материалларын колхозга кайтарта башлады.

Мин үземнекен исбат иттем, чөнки югарыдагы тәкъдимнәр Иске һәм Яңа Көек, Чулпан балаларының язмышын исәпкә алмаган иде. Ферма янында мәктәп салынган булса, балалар, укытучылар, техперсоналны көн саен автобусларда ташырга, көненә фәлән кадәр рейс ясарга туры килгән булыр, укытучыларның тормышын катлауландыруга китерер иде (өй җылыту, мал карау, ашарга әзерләү һәм башкалар). Ата-аналар арасында тынычсызлык тудырыр иде.

Төрле сыйныф укучыларының дәресләре төрлечә тәмамлана. Салкын, буранлы, язгы-көзге пычракларда авылга кайтып йөгергән балалар – күз алдына китерү кыен түгел. Ә язгы ташкыннар вакытында? Елга ярларыннан чыга, бөтен болыннарны су басып китә. Мондый вакытта нишләргә?

Картлар авылның уртасына, калку җиргә мәчет салган. Безгә мәктәпне энә шул калку, чиста урынга, мәчет янына салырга кирәк. Укучы балалар язлы-көзле су, пычрак ярып, кышын салкын бураннарда туңып, тау башына яки Ахтиял белән Истәк арасына салынган мәктәпкә көн дә барып йөри алмаслар. Башлангыч мәктәпләр барлык җиде авылда да бар, аларга мохтажлык юк. Унган борынгы бабаларыбыз сайлаган җиргә мәктәпне салсак, ата-аналар, сабыйлар һәм укытучылар безгә мәңге рәхмәт укыр, дигәч, бар да

ризалашты булса кирәк. 320 урынлык мәктәп проектын карагач, Кәрамхан агай Шәйморатов:

– Нигә безгә П формасындагы мәктәп кирәк? Пнең ике баганасын кисеп ташлыйк. Материал да аз китәр, тиз дә төзелер.

Дөрес, мәктәпне ел саен төзеп булмаганын ул нык аңлый. Мәктәп төзелешенә исемләнгән цемент, кирпеч, урманнан файдаланып, амбарлар, фермалар салу иде аның исәбе.

Проект-смета документларын хәстәрләп, Мәгариф министрлыгында раслатып, мөһер бастырып алып кайткач, Кәрамхан абый Шәйморатов төзелешне башлап җибәрергә ризалыгын бирде. Үзенә хас житезлек белән оештыру эшләрен башлап җибәрде. Прораб итеп Яңавыл шәһәрендә яшәүче Фирзән Динекәевны алып килеп эшкә кушты. 50нче еллар азагында безнең М.Горький исемендәге колхозның җир казый торган техникасы бар иде. Бульдозер килеп, җирне тигезләп, балчыкларны бер як читкә тау итеп өеп куйгач, фундамент таяклары кагылып жеп сузылды. Авылдашым – тракторчы Мәдхәт Муллаяров берничә көндә казып та өлгерде. Сугыш һәм хезмәт ветераны Хәлим агай Вәлиев житәкләгән Рәсимә апа Әхмәтшина, Хәсәнов Рәфкать, Кави Тимергалиев, Нәсимә Фәррәховалардан торган бригада фундамент периметры буенча таш салып төеп тыгызлап чыкты. Бу эштән мәктәпнең югары сыйныф укучылары да читтә калмады. Аннан фундамент салу башланды – тасмалы фундамент, чөнки бина бер катлы гына булачак, фундамент түзәчәк дигән сүз. Эш туктый-туктый булса да, кышын да, җәен дә барды. Төзүче колхозчыларыбыз кирпеч, цемент юклыктан айлар буе тик утыра. Цемент, кирпечкә кытлык булды. Төзелеш материалларына Уфадан рөхсәт кәгазьләре алып кайтып торам. Кәрамхан агай машиналарына төяп, колхоз төзелешләренә ташып бушатып куя. Колхозның төзелешләре бик күп: Бәнәбашта дуңгыз фермасы, Истәктә сыер фермасы, Иске Көектә дә шундый ук ферма. Колхозның төзелеш материалларын иң арзан һәм җинел табыла торган чыганагы – мәктәп тапканнары. Ә мәктәпнең транспорты юк. АТПдан беркетеп бирелгән машиналар эшкә ярарлык түгел, мәктәп өчен яңа машина бүлмиләр иде.

Безнең мәктәп төзелеше дәүләт планына кермәгән, чөнки ул инициатив төзелеш. Шуңа күрә акчаны да, төзелеш материалларын да

калдык принцибы буенча гына бирәләр иде. Кайбер айларда Уфага теләнеп 4-5 тапкыр, бер айны хәтта жиде тапкыр барырга туры килде. Министрлар Советы рәисе урынбасары Нигъмәтжановтан Тәтешле районының мәктәп төзелеше өчен урман делянкасына рөхсәт алып кайттым. Колхоз ул агачларны да үзләштерде. Гел чыршы урманы иде ул. Шунда ук дүрт мең шиферга, 60 тонна цементка, пыялага, тоташтыргычларга да наряд алып кайттым. Рәхмәт инде Нигъмәтжанов белән Уразбахтинга. Сайлауларда мин Уразбахтинның ышанычлысы – «доверенное лицо»сы идем.

Нигъмәтжановтан чыгып килгәндә, аның ишеге төбендә Мәгариф министрлыгының бер хезмәткәрен очраттым, хәле бетеп килеп житкән:

– Синме Яңавыл директоры? Нишләп йөрисең син? Министр Фатыйма Хәмидовна сезне егерменче бүлмәгә чакыра, – диде.

Егерменче бүлмәнең нәрсә икәнен беләм мин – ул Мәгариф министрлыгының канцеляриясе. Анда мәктәпләр өчен кирәкле бөтен товарларга разнарядка бирелә. Мин шатланып барып кердем. Мөгаен, минем мөнәсәбәт буенча берәр нәрсә булганнәр, янәсе.

Житди генә итеп ак чырайлы мөдир (татар хатыны) миннән сорады:

– Сез Яңавылдан килдегезме?

– Әйе, Яңавыл районының Истәк мәктәбеннән.

– Командировкага рөхсәт белән чыгып киттегезме?

– Юк.

– Министр апагыз Фатыйма Хәмидовна кушуы буенча Яңавылга ничә тапкыр шылтыраттык, әмма берсен дә очрата алмадык. Нигә рөхсәтсез чыгып киттегез? Өстәвенә, министрлар Советы рәисе урынбасарына барып кергәнсез. Кем рөхсәте белән? Ни өчен? Фатыйма Хәмидовна Сезне бик каты ачуланды һәм сезне ашыгыч рәвештә табып, командировочныегызны рәсмиләштермичә кайтарып жибәрергә, урында тәртибеңне тикшерергә кушты.

– Без бит 320 урынлы типовой проект белән мәктәп төзибез, инициатив төзелеш ул. Кайдан, кемнән акча яки материал табасың, шуннан аласың. Директор кайгыртмагач, кем кайгырта инде ул төзелешне? Беркем дә китереп бирми йөрмәсәң.

Урта яшьләрдәге мөдир шундый хужалык эшләре артыннан эт

шикелле әлсерәп, кая барырга белмичә, арып, телен асылындырып йөргән директорларны аңлый иде булса кирәк. Ул житди генә:

– Командировочныегызны. Сөйләнеп, күренеп йөрмәгез, хәзер үк кайтып китегез.

Ул командировочное удостоверениега күз йөртеп чыкты да, мөһер басты.

– Роно мөдиреннән рөхсәт алып, юлга чыгарга онытмагыз киләчәктә, – дип мөлаем гына саубуллашты.

Төшке аш вакыты. Совминда Ямадыдан таныш егет эшли. Төшке ашны ашап, шахматта көч сынашалар иде. Мине таныды. Күрештек.

– Миңа Уфада бер кич куныл чыгарга кирәк иде. Кунакханәләрдә урын таба алмадым. Берәрсенә шылтыратмассызмы икән?

Ул Уфа кунакханәсенә шылтыратып, администраторга минем фамилиямне яздырып куйды.

Ямады егете Динов ул вакытларда Башкортстан буенча РСФСРның баш ревизоры булып эшли иде. Соңыннан аны эшкә Мәскәүгә алдылар. Ярдәм иткәнең өчен рәхмәт сиңа, якташ.

Икенче көнне иртән КПССның Башкорстан өлкә комитеты бинасына барып кердем. Мәктәп төзелеше минем шәхси эшкә әйләнде. Ачуланып та куям: үземә йорт салам, бугай! Минем максат – Башкорстан Өлкә комитетының беренче секретаре М.Ш.Шакиров белән очрашып, хәл-әхвалемне сөйләп, мәктәп төзелешен берәр төзелеш оешмасына беркетүләрен үтенеп сорау һәм мәктәп төзелешен тизләтүгә ярдәм итүенә ирешү иде.

Обком ишеген ачып кергәч тә, баскыч өстеннән коридор буйлап сузылган яшел палас күзгә ташланды, аның ике читеннән кызыл тасма сузылган. Ишек төбендә телефон янында, тумбочка артында милиционер утыра. Ул дежур икән.

– Пропуск! – дип сорый ул катгый рәвештә.

– Пропускым юк минем, – дим.

– Пропусксыз ярамый. Сез коммунистмы?

– Әйе.

– Партбилетыгызны күрсәтегез. Кемгә керәсез? Нинди йомыш?

– Беренче секретарьга. Мәктәп төзелеше буенча.

Дежурный миңа бераз карап торды да:

– Барыгыз, керегез, – дип үткәреп җибәрде.

Ул, мөгаен, шундый «чепуха» сорау белән беренчегә керәләрме инде дип уйлады, чөнки минем арттан мыскыллы елмайгандай тоелды миңа.

Әкрен генә атлап, мин баскычлардан күтәреләм. Баскычлары текә түгел. Коридорда, фойеда тып-тын. Салкынча. Монда нормаль температура саклана икән дип уйлап алам. Милиционер өйрәткән юлдан барам. Менә КПСС обкомының беренче секретаре бүлмәсе. Аның ишеген, тирә-яктагы язуларны күрү белән мин дулкынланам. Кабул итүче секретаре бүлмәсенә керәм. Анда берничә кеше секретарьнең кабул итүен көтеп утыра. Шул вакыт чит ил делегациясе килеп керә. Без һаман көтәбез.

– Мидхәт Шакир улы кабул итә алмый, хәзер үк башкалага оча, – диде секретаре.

Коридорда табличкаларны укып, танышып йөргәндә кара тушь белән акка ачык итеп язылган «Школьный отдел» һәм ике кеше фамилиясен укып алдым. «Әһә, менә кайда керергә кирәк миңа», – дип уйлап куйдым.

Ишек шакып, бүлмәгә үттем. Әңгәмәдәшчеләрем миңа аяктан башка сынап карап, урын тәкъдим иттеләр.

– Кайдан киләсез, кем буласыз? Нинди мәсьәлә буенча килдегез? Мин инициатив юл белән 320 урынлык типлы мәктәп бинасы төзүебезне, төзелешнең озакка сузылуын, төзелешкә беркетелгән М.Горький исемендәге колхозның бездән башка да эшләре күплеген кыска гына итеп сөйләп бирдем.

– Кайсы авылдан дидегез әле?

– Яңавыл районының Истәк авылыннан.

– Яхшы, ярдәм итәргә тырышырбыз. Мәгариф Министры белән дә сөйләшеп алырбыз.

Минем эчкә җылы йөгергәндәй булды, бу сөйләшүнең зыяны булмаячак.

Обкомнан чыккач, уйга калдым. Нишләргә? Әлбәттә, Уфа тиклем Уфага килеп, Министрыбызны күрмичә, күңелемдә кайнаган ничәмә сорауга җавап тапмыйча кайтып китү мәгънәсезлек булыр иде. Электән дә Фатыйма Хәмидовна, мине бик яхшы кабул итеп, төзелеш эшләре алып баруымны бик хуплаган иде,

«ярдәм итәрбез», – дигән иде.

Чиратта миннән алда берничә директор басып тора. Фатыйма Хәмидовнадан тиз генә чыкмыйлар. Ул үзенә килгән һәр кешенең тормышы, эше белән кызыксына. Нинди эшләрнең министр кушуы буенча, ниндиләренең министрдан башка башкарылуын аңлатып бирә.

Чират миңа да җитте. Кәгазь өстеннән башын калкытып, ягымлы исәнләшеп, миңа утырырга урын тәкъдим итте. Хәлемне сораштыргач, йомышларымны сөйләп бирдем:

– Мәктәп төзелеше өчен ишек, тәрәзә блоклары, бетон тоташтыргычлар...

– Яхшы, – диде ул. – Төзелеш эшләре белән минем урынбасарым Дерягин Владимир Владимирович шөгыльләнә. – Ул телефон трубкасын күтәрде. – Сезгә Яңавыл мәктәп директоры керер, аның мәсьәләсен унай хәл итсәгез иде. Телефон трубкасын куеп, миңа бик җитди караш ташлады. – Сезгә субординация дигәнне аңларга вакыттыр инде. Моннан соң бездән узып югары инстанцияләргә кереп йөрисе булмагыз. Аңашылдымы? Хәзер Владимир Владимировичка керегез, сау булыгыз.

Мин рәхмәт әйтеп, чыгып киттем. Министрның үзен-үзе тотышы, эчкерсез ягымлы сөйләшүе, эшне тиз һәм анык хәл итүе, гомумән, кешелеклелеге, кечелеклелеге охшады миңа. Олы абзыйларыма кереп йөргәнем өчен, берәү булса чабындырып чыгарыр иде. Юк, Фатыйма Хәмидовна алай итмәде, гафу үтенгәнемне дә теләмәде, кешене пешка итеп түгел, шәхес итеп күрә белә иде.

Менә ни өчен мине эзләгәннәре кылт итеп исемә төште. Бөтен тәнем буйлап эссе кан йөгергәндәй булды. Эсселе-суыклы булып киттем. Димәк, министрга минем сoранып йөрүемне хәбәр иткәннәр.

Дерягин Владимир озын буйлы, озынча ак йөзле, ефәктәй сары чәчләрен шоп-шома итеп тарап куйган. Ул мине бик җылы каршылады.

Мин проект-смета документациясенә күчереп, күпме ишек, тәрәзә блоклары, күпме тоташтыргычлар, тимер-бетон әйберләре кирәклеген алдан язып килгән идем. Эшлекле кеше ул Владимир Владимирович. Охлебинога шалтыратып, әзер блоклар барлыгын

белде дә: «Тиз генә килеп алыгыз, югыйсә бетеп куюы бар», – диде. Мин сораган башка материалларга да наряд язып бирделәр.

Аннары нишләптер әдәбият турында сүз чыкты. «Мертвые остаются живыми» романын бик яратып укыган идем. Менә бәхет, университетта укыганда имтихин билетында да шул сорау эләккән иде. Ул яттан кайбер җөмләләрне әйтә башлый, мин дәвам итәм.

– Оһо, әсәрне яхшы беләсез. Монысы яхшы. Кайда укыдыгыз? – дип сорап куйды. Мин үземнең Казан дәүләт университетында тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлавымны, анда атаклы фән докторлары, профессорлар укытуын әйттем. Философия фәне буенча безне профессор, фән докторы Абдурахманов абый укытты. Үз фәнен бик яхшы белә һәм яратып укыта. Лекцияләр, китаплар белән тулган сырлы кара-саргылт сумкасын өстәл өстенә шап иттереп куя. Зур иде аның сумкасы! Аннары ачык дикция белән, бик аңлаешлы итеп, ике сәгать буе ни дәфтәргә, ни китапка карамыйча, сөйләп дәрес үткәрә иде. Әзрәк кенә уң аягына аксый. Сугышта яраланып кайткан дип сөйлиләр, аксаса да дәрестә дә бер минут утырып тормый. Шундый сәләт биргәч тә бирә икән Ходай кешесенә. Соклана идем, мин ыспай озын гәүдәле юантык кына бу татар кешесенә. Аның лекциясеннән качучы юк, һәркем йотлыгып тыңлый. Мин дә философияне бик ярата идем. Владимир Владимирович белән философик мәсьәләләргә дә кереп киттек. Нишләп шулай килеп чыккандыр, әлегә кадәр аңлап бетерә алмыйм. Бәхәсләшеп тә китәбез. Әллә ул үзе дә университетта укыды микән, үзе укыган шул елларны сагына микән соң? Ул күтәргән мәсьәләләрне белмәсәм, юлым да булмас иде, бәлки. Әлбәттә, ялгыш фикер бу! Мөгаен, ул да министр урынбасары булса да, яшьлек елларын торып-торып хәтеренә төшерәдер.

Юлым булды. Сөенеп, канатланып кайттым.Колхоз идарәсенә бер керәм, ике керәм. Кәрамхан абый мине ишетми дә. Идарәдә кешеләр күп. Шулар белән әңгәмәләшә. Әле телефоннан кемнедер табып, колхоз эшләрен кайгырта. Баш бухгалтер колхоз рәисенә Таганрогтан шылтыратуларын әйтә. Ул тиз генә трубканы ала, шалонга төяп бәрәңге озатканын, шушы көннәрдә барып житәчәген аңлата.

Кемнәр белән генә бәйләнешкә кермәгән иде ул! Бүгенге базар

мөнәсәбәтләрендә аның өчен нинди генә перспективалар ачылмас иде һәм күпме табыш тупламас иде. Ул чын мәгънәсендә экономист иде. Бик уңган, акыллы, булдыклы, талантлы, шул ук вакытта каты куллы оста оештыручы да, житәкче дә иде.

Тагын Истәктән Иске Көеккә бардым. Авыл аралары ике-өч чакырым. Рәис әйтә:

– Мин хәзер Яңавылга чыгам, велосипедың белән мине уза алсаң, иртәгә иртән сәгать биштә машиналар мәктәп төбендә булыр, – диде. Бу шартымны үтәмәсәң, минем машинаны узмасаң, колхоздан машина көтмә.

Идарәдән чыгып, рәис машинага кереп утырды. Аның авыр гәүдәсеннән машина сыгылып куйды. Баһауов Фәнәви – рәиснең шоферы. Мин велосипедымда алардан алдарак кузгалып киттем. Ләкин машина – машина инде ул, тузан чыгарып мине узып китте. Мин машина артыннан чабам, эт шикелле. Бер мәлне машина акрынайгандай булды, мин аны узып каршысына туктадым һәм велосипедтан төштем. Машина да туктады. Истәк әрәмәлегенә килеп житкән идек инде. Аркадан тир бәреп чыкты, чәчләрдән тамчы тама. Кәрамхан абый машина ишеген ачып:

– Ярый син жиңдең, – дигән булды. Иртәгә өч машина булыр. Мин мәктәбем өчен машина алуыма шатлансам да, күңел мыскыл ителүемне күтәрә алмый. Бер түрәнең күңелен күрү өчен югары белемле мәктәп директоры башына велосипед белән юләрләрчә жиңел машинаны куып йөре инде, ә. Йөрәк әрнесә дә, түзәргә кирәк. Нинди генә түбәнчелеккә төшерергә теләсәләр дә, мин башымны имәм, «кечкенә университетымны» салып бетерү өчен көчемне кызганмаячакмын. Истәк авылында үзәктән жылтыла торган бөтен унайлыклары булган проект нигезендә төзелгән мәктәп кайчан да бер, жиз кыңгырауларын чыңлатып, улларын, кызларын чакырып, туган авылымның яме, нуры булып торыр. Изге максатыма барыбер ирешәчәкмен.

Әллә ул минем директор булуымны өнәп бетермәде, минем үтенечләремә тиешле игътибар биреп бетерми иде. Болай гына, ачу килгәндә әйтүем. Колхоз – күп тармаклы хужалык, бик катлаулы проблемаларны хәл итәргә кирәк, рәиснең уенда мәктәп кенә мени!

Көз. Гадәттәгечә бәрәңге чыгарабыз. Ул елларда мәгариф мини-

стры приказы нигезендә укучыларны, укуларыннан туктатып, колхоз эшләренә кушалар иде. Быел бәрәңге бик нык уңды. Мәйданы да зур. Безнең мәктәп укытучылары һәм укучылары ике атна гына түгел, дүрт атна бәрәңге чыгардылар. Укучылар да, укытучылар да тәмам алҗадылар. Эшләрлек хәлләре калмады. 65 га мәйданнын бәрәнгесен, 10 га мәйданның азык чөгендерен җыйнап фермага ташып куйдык. Аннан соң программаны ничек үтәргә кирәк, укучыларның төп эше уку булуын истән чыгармаска кирәк. Менәменә беренче чирек тәмамланырга тора. Укучыларга нинди белем бирдек инде беренче чиректә? Оценкалар юк, ә чыгарырга кирәк. Авыл Советында җыелышып сөйләштек, тик Кәрамхан Шәйморатов укучыларны эштән туктатуга каршы чыкты. Рәис мине куркытып мәҗбүр итәргә тырышып, ачуланып, беренче секретарьгә шылтыратты. Бераз сөйләшкәннән соң, Кәрамхан агай телефон трубкасын миңа тоттырды:

– Мә сөйләш.

Сөйләштем мин КПСС район комитетының беренче секретаре Закир Фазыл улы Мөхәммәтшин белән. Мин аңа мәктәптә укучыларның дүрт атна буена колхозда эшләүләрен, тиздән беренче чирек тәмамланачагы, балаларның эшләрлек хәлләре калмаулары турында әйттем.

– Бәрәңге җирдә калса, син җавап бирәчәксең, – диде катгый итеп беренче секретарь.

– Мәгариф министры приказы булса, яки райком исеменнән язма рөхсәт кәгазе бирсәгез...

– Мин ничек бирим ди инде андый боерык! Трубканы рәискә бирегез.

Шушы сөйләшүдән соң мәктәпне яңадан колхозга эшкә кушучы булмады.

# Редакционные байки

## Начало пути



В 1957 году после окончания Казанского госуниверситета вернулся в родное село Истяк с огромным желанием верой и правдой служить малой родине. Не успел отвыкнуть от студенческой жизни, как пригласили работать в редакцию газеты «Путь Октября». Редактор Мазгар Ахатович Саяпов принял меня тепло, ознакомившись с документами, сразу же решил проблему с жильем – предоставил одну из комнат второго этажа редакции (его правое крыло использовалось как жилье для сотрудников). Взяли меня с испытательным сроком на один месяц.

В коллектив влился легко, знал в редакции почти всех, будучи школьником, часто заглядывал к журналистам то со стихотворением, то с информацией в руке. Василий Рябов, Яват Яруллин, Агзам Тимержанов (А. Тимер) – ответственный секретарь, Г. Самарцев – заместитель редактора, П. Ф. Патрикеев – завотделом сельского хозяйства, Согда апа Габдиева –литсотрудник. Все скромные, открытые, настоящие мастера пера, терпеливо и настойчиво учили они меня азам журналистского мастерства.

Месяц прошел незаметно. Седьмого октября на бюро райкома КПСС меня утвердили на должность заведующего отделом писем.

В этот же день пригласили в райисполком, назначили уполномоченным при отчете заведующего клубом села Истяк. На другой день состоялась встреча с пожилыми революционерами, 19-20 октября в районе должна была пройти комсомольская конференция. Ожидались командировки в Карманово, Ижболдино, Кичикир, Ямады... Завертела, закрутила меня журналистская жизнь, о которой, собственно, и мечтал с детства.

## Мои любимые песни

Была такая раньше передача на радио – «Ваши любимые песни». Там и услышал ставшую любимой песню «Не забывай» и постоянно ее напевал. А однажды взял и запел ее прямо на рабочем месте: «Не забывай родные дали, родных небес простор и высь. Не забывай, о чем мечтали, и в чем с тобой мы поклялись... Своей любви, своей судьбы не забывай!..»

Сотрудники редакции недоуменно на меня смотрели, но слушали внимательно, а когда закончил петь, все громко засмеялись. Немногословный, острый на язык Самарцев сквозь смех произнес: «Вот артист, во даешь! То, что она говорила вчера вечером, все еще в твоих ушах, наверное, звенит». Масла в огонь подлил Агзам Тимержанов: «Точно! Если в сердце кипит горячая любовь, не только запоешь – запляшешь». Даже всегда улыбчивая и мягкая Согда апа не промолчала: «Душа его поет. Понять можно молодого человека, скучает, наверное, по своей любимой. Казань-то далеко!»

Появление редактора спасло мое положение: все разошлись по своим рабочим местам, застучали пишущие машинки...

## Крутится, вертится...

Яркие лучи солнца проникают через оконное стекло, передразнивая молодое сердце. Легко и радостно на душе. Работа нравится, научился уже печатать на машинке. Когда все спорится, когда окружают тебя хорошие люди, когда к тебе относятся с доверием и уважением, на добро отвечают добром, ей-богу, душа поет. Иногда начинаю: «Крутится, вертится шар голубой...» Сидящий напротив Павел Федорович подхватывает мою песню. С азартом, но негромко повторяем: «Крутится, вертится...» А сами смеемся от радости.

Жизнь хороша, и жить хорошо!

## «Дайте мне передовой колхоз!»

Рабочий день на исходе. Материалы в набор сданы, сотрудники редакции расходятся домой. А я – дежурный, значит, должен просмотреть полосы, исправить ошибки, если есть, и подписать номер в печать. Вдруг забегает в кабинет наборщик с матрицами и выпаливает: «На второй полосе не хватает материалов, срочно информация



нужна!» Как назло, ни одного запаса на столе нет. Пробую созваниваться с колхозами, звонков десять сделал, никто трубку не берет – время уборочной страды.

Отчаявшись, звоню на телефонную станцию: «Алло, алло! Почта, дайте мне какой-нибудь передовой колхоз, – кричу в трубку. И добавляю: Срочно!»

Телефонистка, недоумевая, переспрашивает:

– Какой-какой? Передовой?

– Так точно, передовой колхоз!

– У меня названия всех колхозов есть, «Передового» там нет, – говорит она и кладет трубку.

С соседнего кабинета приходит Яват Яруллин, он, как и я, жил в редакции. К счастью, у него был готовый материал, его я сразу же отнес в типографию.

– Передовой колхоз, говоришь, да? Откуда телефонистка это будет знать?!

– Да я просто так, можно сказать, пошутил. Это-то уж я сообразил бы, – говорю Явату.

Газета ушла в печать вовремя, но коллеги каждый раз передразнивали меня, называя «передовым колхозом». Делали они это как-то по-доброму, обижаться на них и в голову не приходило.

## Уроки А. Тимера

Кто бы ни пришел в редакцию, Агзам Тимер всех встречает с улыбкой. Так разговаривает с человеком, что тот готов поделиться самым сокровенным. То он смеется заразительно, то песенку напевает. Несмотря на то, что был довольно грузным, отличался легкостью на подъем. Непонятно, как он успевал, но на его столе всегда лежала куча заготовок. Писал он также рассказы, стихи. Однажды, когда вместе обсуждали после работы его литературные творения, спросил его:

– Тимер ага, вы всех что ли в районе знаете? Каждого встречаете,

как родного человека, провожаете до калитки. Зачем вам это нужно? И как вы успеваете?

– Хорошо, что сам заговорил, – сказал он. – Давно хотел об этом с тобой поговорить. Если есть желание, на все можно время найти. Что в нашей работе главное – это любить людей. Может, человек за всю жизнь один раз в редакцию придет, надо его по-доброму принять. Помочь, если нужно. У него должно остаться хорошее впечатление о журналистах, редакция – это не шарашкина контора. А самое главное, он ведь газету не просто так получает, а выписывает за деньги, значит, наш кормилец! Если есть проблемы, надо помочь решить. И улыбку нельзя жалеть, читателю не нужен зарывшийся в бумагах писака, ему живой человек нужен.

– А если улыбаться совсем не хочется?

– Эх, Фазлый, Фазлый (так он меня называл), даже этого что ли не знаешь? Для этого не надо университеты кончать: подбородок чуть-чуть опускаешь вниз, показываешь передние зубы, немного растягиваешь губы. Замечательная улыбка получается! Улыбаться надо научиться. Денег это не требует, а людей располагает.

## Будильник

Командировки – неотъемлемая часть журналистской жизни. Очередная была в деревню Кичикир. «Поедешь в летний лагерь, будешь делать хронометраж рабочего дня. Возьми с собой часы. Выехать придется с вечера», – сказал мне Мазгар Ахатович.

Выехать – это значит на перекладных (используя разные способы передвижения – от ред.). Добрался, нашел заведующего фермой, оказался удивительно открытым, добрым человеком. У него и заночевал. Двое суток находился в Кичикире. Лагерь располагался в живописнейшем месте. И работали там по-настоящему хорошие и красивые люди, до сих пор вспоминаю о них с ностальгией. Вернувшись, с удовольствием написал большую статью «Девчонки с лагеря». Красота природы, доброта людей так подействовали на меня, что хотел даже пьесу написать, но руки не дошли.

По приезде вспомнил, что брал с собой будильник, но достать его из сумки духу не хватило – завфермой оказался точнее любых часов. На всю жизнь мы остались с ним добрыми друзьями.

Как только переступил порог редакции, навстречу вышла

Согда апа Габдиева:

– Уже соскучиться успели, где пропадал? Испугались, что захомутали тебя сельские красавицы, они ведь такие – попадешься в сети, не выпутаешься, – сказала она, смеясь, а потом шепотом добавила: – Раскрасавица твоя приходила, Незабывай, соскучилась, наверное, бедняжка...

Уши мои от стыда залились багровой краской, на лбу выступили холодные капли пота.

– Не стала говорить, что на других заглядываешься, обоих пожалела. Вы же мне как дети...

## «Статью ожидаем к . . .»

Недолго мне пришлось кипеть в редакционном котле, хотя и был без ума от своей работы, зауздали быстро. В августе 1958 года, вызвав в райком, заставили расписаться под приказом о моем назначении директором Истякской семилетней школы. В те годы заведовал отделом образования Касим абый Гайданов. А моя любимая учительница Фаузия Ямалтдинова (Ишмакова) была секретарем райкома.

Связь с редакцией поддерживал всегда. Редкий раз, бывая в райцентре, не заглядывал к бывшим коллегам. Они меня тоже не забывали, частенько давали задание. Одно из них сохранилось:

*«Уважаемый Фазлыев М.!*

*Редакция просит Вас подготовить статью на тему «Куда будут ссыпать картофель?». В статье желательно отразить наличие картофелехранилищ, их состояние, обеспечивают ли надежное хранение. Если же их недостаточно, какие принимаются меры.*

*Статью ожидаем к 10 июня 1959 года. С приветом В. Рябов».*

Письмо было написано 2 июня.

***

Работа в редакции стала для меня большим жизненным подарком. Много новых людей узнал, добрых друзей приобрел, главное – прошел через такие испытания, что потом всю жизнь вспоминал. Спасибо вам, мои родные, ваши имена в моем сердце всегда. Доброта не забывается, да и не пропадает никуда.

*«Янаульские зори», № 59 от 28 июля 2017 г.*

*Перевод А. Хатмуллиной. Иллюстрации Г. Тимершиной.*

# Гомер юлдашым Рәшидәгә



*Күңелемнең сахрасында*
*Бердәнбер чәчәгем син.*
*Син булганда дөньям матур,*
*Хәтта оҗмахларга тиң.*
*Кайчагында баш өстемдә*
*Куерса кара болыт,*
*Таратасың аларны син,*
*Игелекле җил булып.*
*Чыксам юлга, хәстәрләкләп*
*Мине озатучым син.*
*Кайгы килсә, җан әрнесә,*
*Мине юатучым син.*
*Изгеләр затыннанмы син,*
*Әүлияме әллә син?*
*Әйтмәсәм дә беләсең ич*
*Уйларымның һәммәсен.*
*Көнләшеп тә куям кайчак*
*Акыллы булганыңа.*
*Балаларның өзгәләнеп,*
*«Әнкәй!» дип торганына.*
*Уңганнар гына туадыр*
*Яңа ел иртәсендә.*
*Йөрәгем типкән чагында*
*Табынам, иркәм, сиңа.*

# Родная моя сторона

Как красивы наши родные края! Вот Бог дал так дал! Всю свою жизнь не перестаю восхищаться и гордиться красотой родной деревни Истяк, привольно раскинувшихся полей и лугов, хотя и небольшой, но рекой Каймашой. Моя родная земля – самое красивое, прекрасное место, где есть все для жизни, для ведения хозяйства. Слава богу, на этой земле не бывает сильных бурь и ураганов (не считая 1935 года), землетрясений, которые принесли бы неисчислимые потери и беды. Пусть и в дальнейшем будущие поколения не видят природных бедствий, а засучив рукава работают, растят здоровых детей. Мне приходилось слышать такую молитву: «Боже, дай нам, мусульманам, благоденствия». Пусть их желания сбудутся.

Вот посмотрите. Вдоль асфальтовой дороги, которая идет из Янаула в деревню Истяк, стоят лесополосы, с обеих сторон дороги, напоминая зеленое море, радуют глаз пшеничные поля. Если хотите, можно идти и по прямой дороге, белые березы приветливо встретят вас и проводят до самой деревни.

После аэропорта, через несколько сот метров, большая дорога резко поворачивает к юго-востоку. Думаете, почему? Раньше там был овраг Бидерале. Может быть, раньше он был речкой. Его называли Глубокий Лог. Во время весеннего половодья воды, не вмещаясь в берега, урча и злясь, текли настоящей рекой. Переправиться через нее ой как было нелегко.

Когда спускаешься с возвышенности, между деревнями Ахтиял и Истяк простирается ровная, как стол, долина.

Разрезая долину на две части, словно серебристый кушак, извиваясь, течет небольшая речка Каймаша. Наша речка весной словно забывает о сдержанности, выходит из себя, принося с собой большую талую воду, льдины, заливает луга, даже несколько дней беснуется в одном конце деревни, называемой «аръяк», т. е. «противоположная сторона», словно кичась сво-

ей силой, мощью, приносит на улицы большие льдины, затапливает дома и огороды. Бывает, что мои односельчане, оберегая свой скот, постройки, проводят бессонные ночи. Затем Каймаша-су успокаивается, как будто прося прощения, мол, я ошиблась, возвращается в свои берега и течет себе, течет.

На правой стороне речки, рядом с деревней Ахтиял, в голубой дымке виднеется Биздерган-тау. На ее вершине шумят ельник и сосновый лес. На нашей стороне, наверное, нет выше другой горы, чем Биздерган-тау. Гора Иван-тау, что расположена у деревни Сабанчи, будет пониже.

А эта маленькая речка взяла в свое лоно несколько деревень. Давайте прислушаемся к географическим названиям вокруг деревни. Луг, расположенный за околицей, называют «балан куак» («калиновый куст»). Правда, сегодня там не найдешь ни одного куста калины, даже сухого сучка.

Пусть там нет кустов калины, но мы продолжаем называть его по-старому, храним, не теряя, название, данное предками.

Чуть дальше есть крутой и высокий берег – «кызыл яр» («красный берег») его название. В детстве катались там на лыжах, санках до ночи, только шум-гам стоял. Бывало, возили туда даже конные салазки. Дальность не пугала, катались на конных повозках и с Биздерган-тау. О катании на лыжах и не говорю. Если выйдешь из деревни и направишься к железной дороге – «этэч болыны» («петушиный луг»), потому что там раньше была куриная ферма. А луг, что направо, называем «сад», т. к. там после войны располагался плодовый сад.

Если идти в Истяк со стороны Янаула по железной дороге, попадаешь на «луг женщин» («хатыннар болыны»). Почему же его так назвали? Почтенный мой односельчанин, 82-летний уважаемый аксакал Мухаматнур Шакирович Шакиров (ныне уже покойный), со своей женой Назифой апа в 1988 году так объяснили мне происхождение названия.

– Галимьян Хасанов, Ямалетдин, Кашшаф Ахмадиев, собираясь вместе, часто рассказывали историю, где звучали слова «Бой женщин». В древние времена сильное войско женщин

прошло именно через этот луг. Наверное, дрались за землю. За железной дорогой были и могилы. У реки Буй в Каймашинском лугу тоже были их могилы. По дороге в деревню Таш-Елга (раньше из Истяка через лес ходили напрямую) во время раздела земли наткнулись на человеческие кости. Собрав их вместе, похоронили в одном месте. И в горах за Буем были бои. Похоронены посередине луга на возвышенности. Там была дубовая роща. Сейчас она распахана, разровнена. Раньше называли «кладбище». На этих землях я и сам бывал несколько раз, своими глазами видел и ту возвышенность, и ту рощу дубовую.

Да, река Буй течет и течет, то притихнув, о чем-то думая, то шумя и бурля. Она, как свидетельница тех боев, может быть, рассказывает о седой истории. За землю, за родину выходили в поход не только мужчины, но и красавицы Вселенной. Может быть, Буй слышал и их имена. Но нам не суждено узнать, какие тайны, какие имена хранятся в шуме реки.

А «Кызлар тугае», «Ташлык», «Табыр», «Арлян-елга буе», «Эрэмэлек» и другие – как красиво звучат эти названия! Они еще долго сохранятся в памяти поколений.

Названия деревень, названия местностей – это золотые нити, связывающие поколения друг с другом. Их надо изучать, понять их глубокий смысл и довести до молодых – это задача дедов и бабушек, мам и пап, учителей и воспитателей. Эти названия воспитывают любовь, преданность своему родному краю и чувство гордости за нее.

# Серле фонарь

Ул вакытларда авылда культура эшләрен ныклап җәелдереп җибәрү өчен көчләр житәрлек түгел иде әле. Шуна күрә революцион бәйрәмнәрне үткәрү өчен волость күләмендә яшь совет интеллигенциясе – укытучылар, китапханәчеләр, волость җитәкчеләре Байгужа авылына, волость үзәгенә, җыелганнар. Истәк башлангыч мәктәбе укытучысы Бикметов Кави Гариф улына Бөек Октябрь бәйрәменә биш көн кала чакыру кәгазе килгән. Кавида бәйрәмгә карата нинди дә булса бүләк алып бару турында бик күптән фикер яши иде. Менә бер көнне ул, бер-ике баланы дәрестән соң мәктәпкә чакырып, «серле фонарь» ясарга булды. Ә чакыру кәгазе икенче тапкыр да килде. Өченче көнне, эш тәмамлану алдында торганда, мәктәп янына жигүле ат килеп туктады. Мәктәпкә мылтыклы кеше килеп керде. Дәшми-тынмый гына ул бәйрәмгә бүләк эшләгәннәрен карап торды. Эш тәммлангач, балалар өйләренә кайтып киттеләр. Милиционер кулындагы язуны Кавига бирде. Анда: «Бикметовны алып килү, милиционер иптәш, сиңа тапшырыла», – дип язылган иде.»Серле фонарь»ны култык астына кыстырып, ул чанага тезләнеп кенә утырды да, өч кеше бер атта Байгужага юл тоттылар. Килеп җиттеләр. Волисполкомга керделәр. Ләкин икенче катка түгел, беренче каттагы аркылы тимер салынган ишекне ачып бүлмәгә үттеләр. Кави табуреткага утырды, «серле фонарь» исә өстәл өстенә урнашты. Милиционер басып тора.

Күп тә үтмәде, югары каттан Бөредән килгән вәкил һәм бер укытучы бүлмәгә килеп керделәр. Алар да дәшми. Кави да дәшми. Беразвакыттан соң өстәлдәге «серле фонарьга» күзләре төште.

– Бу нәрсә? Син алып килдеңме?

– Әйе, иптәш Уранский (волость күләмендәге оештыручы-инструктор Хафиз Харис улы Фәрхетдиновның кушаматы, ул Иске Көек авылыннан), – диде Кави, ачык итеп. – Октябрь бәйрәменә бездән хезмәт бүләгебез булыр дип, укучыларым эшләде. Озаккарак сузылды. Гафу итәрсез инде.

Уранский белән Гафуровның йөзләре ачыла башлагандай



***Бикметов Кави Гариф улы. Бөрө, 20 гыйнвар 1919 ел.***

иткәнен күргәч, укытучы фонареның серләрен күрсәтә башлады. Шырпы сорап алып, фонарь эчендәге шәмгә ут кабызды. Бүлмәнең караңгырак почмагына алып барып, бер ягын күрсәтте. Анда: «Яшәсен Октябрь революциясе!» дип язылган. Икенче ягында исә: «Яшәсен Коммунистлар партиясенең милли политикасы!» – дип язылган. Өченче ягында урак һәм чүкеч төшерелгән. Болар барысы да кып-кызыл булып күренәләр.

Хафиз Уранский, үзе белән «серле фонарь»ны алып иптәшләрен югары катка чакырды.

– Әйдә Бикмәт. Безне анда эш көтә, – диде ул.

Берничә сәгатьтән демонстрациядә йөртү өчен эре хәрефләр белән лозунглар язылды, кызыл флаглар, төрле плакатлар әзерләнде. Революцион җырларга репетиция үткәрелде. Кич концерт кую өчен кирәкле материаллар булдырылды.

7 ноябрь. Төрле урыннарда: Волисполком, мәктәп, авыл шурасы (Советы) биналарында кызыл флаглар җилферди. Демонстрация алдында – укучылар, аннары хезмәткәрләр, авыллардан җыелган халык. Революцион җырлар җырланды, Волисполком алдында зур митинг булды.

Кич белән олы яшьтәгеләр өчен гомум көч белән бәйрәм концерты куелды. Концерттан алда Хафиз Уранский «Октябрь революциясе авылга, вак милләтләргә нәрсә бирде?» дигән темага доклад ясады.

Бөек Октябрь Социалистик революциясенең өченче елы моннан 64 ел элек кенә шулай зур хәзерлек белән һәм халыкның актив катнашлыгында үтте, район тарихында онытылмас бер күренекле вакыйга булып кереп калды.

# Гомернең онытылмас мизгелләре

«...Балалар үзебезнең гаилә өчен хатирәләр китабы язуымны үтенделәр. «Башланган эш – беткән эш», дип, кәеф булган араларда сызгалый башладым. Ниһаять, бер чама истәлек төгәлләнде. Моны якын дуслар укысалар да гөнаһ булмас, дип Сезгә юллыйм...»

Шамил абыйдан әнә шундый хат һәм аның китап итеп чыгарылган истәлекләре килеп төште. «Онытылмас мизгелләр» дип аталган бу китапны кат-кат укыдык. Туганнарыбыз, күршеләребез дә укып чыкты.

Нефтекамадан туган авылы Истәккә ел саен сабантуйларга кайтып, якташларының хәл-әхвәлен белешеп йөрүче күренекле педагог, фронтовик, язучы һәм галим Шамил абый үтә тыйнак кеше, үзе турында сөйләми. Шунлыктан аның турында аз белүебез дә гаҗәп түгел.

Әдәби алымнарны оста файдаланып язган документаль повестендә автор үзенең сиксән сигезеллык гомерен мавыктыргыч итеп тасвирлый. Бала тәрбияләү, туган тел һәм әдәбият укыту буенча фикерләр кызыксынып укыла.

Шамил Әкрам улы Әхтәмов 1917 елның 18 апрелендә Истәк авылында мулла гаиләсендә туган. Әтисенең бай китапханәсендәге әдәби-рухи мирас (анда Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Әфгани, Сократ хезмәтләре дә була) белән бәләкәйдән үк таныша, вакытлы матбугатны укып бара, үзе дә хикәяләр, пьесалар язып карый.

Шамилнең бала чагына гражданнар сугышы, 1921 елгы ачлык, НЭП чоры, коллективлаштыру еллары туры килә. Свердловск педтехникумында, Казан пединститутында укый. Бөек Ватан сугышында Мәскәү өчен барган аяусыз алышларда каты яралана. Госпитальдән госпитальгә күчеп, Себердәге Кемерово

шәһәренә кадәр барып чыга.

8 ай кузгалмыйча чалкан ятып, берничә авыр операция үткәреп, 13 ай дәваланып Истәккә кайтып төшә. Абыйсы Назим, энесе Наил дә сугыш корбаны булган. Авылга Шамилнең дә үле хәбәре килгән.

Мәктәптә укыту бүлеге мөдире булып эшләгәндә Шамил Әхтәмовның аягындагы ярасы ачылып, урын өстенә егыла. Бераз савыга төшкәч тәүдә колхозда, аннары колхозара гидроэлектростанциядә бухгалтер булып эшли. Шуннан үзенең һөнәре буенча Мәсәгуть мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта башлый. Агитатор да, лектор да, үзешчән артист та. Әмма хатыны белән балалары яшәгән авыл ерак, яннарына еш кайта алмау үзәген өзә.

Ниһаять, аны Истәк җидееллык мәктәбенә уку-укыту бүлеге мөдире итеп тәгаенлиләр. Биредә укытучыларның мөстәкыйль һәм иҗади эшләренә игътибар итә. Яңавыл урта мәктәбенә күчкәч, бу алымны киңрәк куллана башлый, Китап укучылар конференцияләре, әдәби кичәләр, диспутлар үткәрелә, әдәбият түгәрәге оештырыла, «Яшь иҗатчы» кулъязма журнал чыгарылып, анда укучыларның әсәрләре урнаштырыла. Укучыларның иҗат эшчәнлеге елдан-ел активлаша, осталыклары арта. Уку елы ахырында башлап язучыларның иҗатына багышланган кичә үткәрелә, концерт куела. Шамил Әхтәмов татар теле һәм әдәбияты укытучылары секциясе җитәкчесе итеп билгеләнә.

1957 елдан ул Башкортстан укытучылары съездында катнаша. «Мәктәптә әдәбият түгәрәге һәм укучылар иҗаты» дигән темага чыгыш та ясый. Аның эш тәҗрибәсе хупланып, Башкортстан Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасына лаек була. Мәктәп Татарстан һәм Башкортстан язучыларын укучылар белән очрашуларга чакыра. Казаннан Риза Ишморат, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Нәби Дәүли, Мәхмүт Хөсәен, Әдип Маликов, Сажидә Сөләйманова, Шәриф Хөсәенов, Уфадан Мостай Кәрим, Гайнан Әмири, Нажар Нәҗми, Шәриф Биккол, Муса Гали, Әнгам Атнабаев, Гыйлемдар Рамазанов, Рәгыйдә Янбулатовалар килә. Очрашу

ике тугандаш республиканың әдәбият бәйрәменә әйләнә.

Күренекле әдипләрнең үзләренә шундый игътибарлы булуы Шамил Әкрам улын канатландырып җибәрә. Ул укытуны фәнни эшчәнлек белән бәйләп алып бара. Үзенең тәҗрибәсе турындагы хезмәтләре Уфа һәм Казан матбугатында дөнья күрә. Ике республикада үтүче фәнни-гамәли конференцияләрдә докладлар белән чыгышлар ясый. 1961 елда РСФСР Педагогия фәннәре академиясе Милли мәктәпләр институтының штаттан тыш хезмәткәре эшен башкара. Тагын бер елдан Татарстан Мәгариф министрлыгы аны 9нчы сыйныфларга дәреслек язу өчен филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллинга автордаш итеп чакыра. Дәреслекнең Г. Камалга, Г. Тукайга, Г. Коләхмәтовка багышланган бүлекләрен Шамил Әкрам улы яза. 1964 елда аның «Мәктәптә Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнү» дигән китабы басылып чыга. Шул ук дәвердә «Урта мәктәпнең югары сыйныфларында татар әдәбияты методикасы» проспектын төгәлләп Милли мәктәпләр фәнни-тикшерену институтына тапшыра. 1963 һәм 1965 елларда РСФСР Педагогия фәннәре академиясе оештырган укуларда чыгыш ясый. Укулар жюрие аны Мактау грамотасы һәм значок белән бүләкли. Аның чыгышы соңыннан «Совет мәктәбе» журналында басылып чыга.

1967 елда җәмәгатьчелек Шамил Әкрам улының 50 яшен билгеләде. Татарстан Мәгариф министрлыгы һәм укытучылар белемен күтәрү институты коллективы котлавында юбилярның педагогик эшчәнлегенә югары бәя бирелә: «Татар әдәбиятын укытуны камилләштерүдә Сезнең хезмәтегез аеруча зур. Татарстан һәм Башкортстан матбугатында, фәнни-гамәли конференцияләрдә ясаган тирән эчтәлекле чыгышларыгыз һәм аерым хезмәтләрегез шул турыда сөйлиләр...»

Башкортстан Мәгариф министрлыгыннан, тармак профсоюзы өлкә комитетыннан, Яңавылдагы оешмалардан да тәбрикләүләр килде. «Совет мәктәбе» журналында юбилей турында хәбәр һәм фото басылып чыкты. Казаннан филология фәннәре докторы Нил Юзеев: «Сезнең кебек инициативалы, белемле һәм дәртле укытучылар күбрәк булса, әдәбиятны укыту күп

мәртәбәләр яхшырак булыр иде...» – дип язды.

Сөекле хатыны Мәмдуха апа һәрвакыт оста киңәшчесе, тугрылыклы таянычы һәм ярдәмчесе булды. Алар менә дигән дүрт бала тәрбияләп үстерделәр. Өлкән кызлары Роза Казан педуниверситеты доценты, педагогия фәннәре кандидаты, кечеләре Рәмзия әниләре юлыннан китеп, югары белемле авыл хуҗалыгы икътисадчысы, бухгалтеры һөнәрен алды, уллары Илдар белән Илгиз абруйлы медицина хезмәткәрләре булдылар.

«1996 елның февралендә безнең олы юбилеебыз булды, – дип яза Шамил Әкрам улы. – Гаилә корып яши башлавыбызның 50-еллык бәйрәмен күңелле итеп үткәрдек. Балалар, кияүләр, киленнәр, оныклар – 18 кеше җыелдык. Табын ямьләнде, әйтерсең лә төрле төстәге аллы-гөлле чәчкәләрне тезеп куйганнармы ни! Музыканың йөрәк түренә үтеп кергән моңлы тавышлары яңгыраганда безне хөрмәт итеп, тирән эчтәлекле чыгышлар булды, тостлар әйтелде, бүләкләр бирелде. Бу тамашаларны тыңлаганнан соң без Мәмдуха белән икебез бер-ике дистә елга яшәргәндәй булдык».

1998 елның 30 июне Әхтәмовлар гаиләсенә иксез-чиксез кайгы китерде. Шамил абыйның тормыш иптәше якты дөньядан китте.

Шамил Әхтәмов моннан күп еллар элек Ырынбурдан фронтка киткән. Муса Җәлил эзләренә басып йөргән, шагыйрь һәйкәлендәге түбәндәге шигъри юлларны укыган:

Батыр үлә үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исемең калсын үзең үлсәң дә
Тарихларда укып мактарлык.

***Бу юллар Шамил Әхтәмовның үрнәкле,***
***матур гомеренә ишарә сыман.***

# История в лицах

Ахмет Мухтарович Асхадуллин родился 4 апреля 1895 года в деревне Старый Куюк Байгузинской волости Бирского уезда Уфимской губернии, по национальности – башкир. Его отец Мухтар агай, как и односельчане, занимался землепашеством и скотоводством. Семья была большая – десять детей: шесть сыновей и четыре дочери. Чтобы прокормить семью, ему приходилось батрачить.

– Отец был очень трудолюбивым человеком, имел свои убеждения, придерживался передовых взглядов, – вспоминает живущая в Старом Куюке Гильмисорур Асхадуллина. – Он вставал очень рано, поднимал всех нас, спящих обычно на полу, каждому давал задание, а потом проверял его выполнение. Хоть сам был безграмотным, но стремился дать детям образование. Отец был очень строгим, а вот наша мама Гульчира, родом из Уракаево, отличалась кротким нравом, добротой, сердечностью.

Среди десяти детей Ахмет (мулла нарек его Муллахметом) был старшим. И ему больше других приходилось работать с отцом. Он пахал землю, бороновал, сеял, жал, заготавливал корма для скота.

До 1913 года Ахмет жил с родителями, закончил начальное училище на татарском и русском языках. В тот же год поступил учиться в Аряжское высшее начальное училище Пермской губернии, а за год до окончания его забрали на воинскую службу, отправили на румынский фронт. Там он служил до декабря 1917 года. В январе 1918 года Ахмет поступил на учительские курсы в Бирске, но закончить их не успел. Уже в октябре его направили учителем в Старый Куюк. Но и здесь он долго не задержался. В апреле 1919 года Асхадуллин уходит добровольцем в дивизию Азина в составе 28 армии Восточного фронта. Шла гражданская война.

После разгрома Колчака Ахмет Асхадуллин воюет против Деникина на Западном фронте (в Польше), до июня 1921 года ведет партийную и культурно-просветительную работу в Красной Армии. Вернувшись на родину, он работает членом исполнительного комитета Байгузинской волости, а уже в июле его избирают председателем исполкома. На этой должности он проработал до



*А. М. Асхадуллин в кругу семьи.*

марта 1923 года. В последующем трудился инспектором отдела образования Бирского кантона (1923-25 гг.), заведующим финансовым отделом (1925-29 гг.), председателем исполкома Бирского кантона, народным комиссаром (по нынешнему – министром) финансов Башкортостана (1929-31 гг.), народным комиссаром земледелия Башкортостана (1931-32 гг.), секретарем областного комитета ВКП(б) по снабжению (1932-34 гг.), с 1935 года – народным комиссаром земледелия Башкортостана.

А.М. Асхадуллин – кандидат в члены Совета национальностей СССР, член ВЦИК XV, XVI созывов. Он вершил большие дела, пользовался авторитетом среди людей, строил планы. Но над ним уже сгущались тучи. 14 сентября 1937 года его арестовали.

На наш запрос из Государственного Комитета безопасности Башкортостана пришел ответ за № 10/2-28619 от 25 апреля 1991 года, в котором говорится: «...арестован по ложному обвинению в контрреволюционной деятельности буржуазно-националистических организаций Башкортостана и вредительстве».

Решением тройки НКВД БАССР 15 ноября 1937 года А. Асхадуллин приговорен к высшей мере наказания – расстрелу. Приговор приведен в исполнение 27 ноября 1937 года.

Предположительно А.М. Асхадуллин похоронен на Сергиевском кладбище Уфы. Точное место захоронения неизвестно, т.к. в те времена в известность об этом никого не ставили.

Президиум Верховного суда Башкирской АССР 21 мая 1956 года, пересмотрев дело Асхадуллина А.М., отменил решение тройки НКВД БАССР от 15 ноября 1937 года и реабилитировал его. Извещение о реабилитации вручено его дочери Рее Ахметовне Асхадуллиной 29 мая 1956 года.

Из-за ложного доноса, клеветы жена и трое дочерей Ахмета Мухтаровича, его родные потеряли дорогого человека, были обречены на трудности и горе, а Башкортостан лишился честного, авторитетного и государственного деятеля.

Жена Асхадуллина – Кафия Хайретдиновна родом из Карманово. Учительница, преподавала и в деревне Куюк. Ее, как жену врага народа, в Уфе нигде не брали на работу по специальности. Чтобы вырастить и воспитать троих маленьких дочерей, Кафие апе приходилось наниматься на разные работы: мыла полы, стирала, была уборщицей.

Пострадала и родная сестра «врага народа» – Хамдия апа. 30 ноября 1937 года ее осудили на 10 лет тюрьмы, которые она отсидела вместе с малолетним ребенком (другой ребенок умер в тюрьме). Постановлением Верховного Суда Башкирской АССР от 28 мая 1965 года за отсутствием состава преступления Хамдия Мухтаровна Асхадуллина полностью реабилитирована.

– Для родственников врага народа работы нет, говорили нам. И даже на учебу не принимали, ходили раздетые, разутые, – вспоминает Гильмисорур апа, а на ресницах блестят слезы. – Где контрреволюционные документы? – требовали с нас и перевернули весь дом, искали в подполе, разворотили потолок. Что мы пережили – не пересказать. Не жили – только мучились. Даже где могила брата не знаем. А ведь жизнь человеку дается только один раз, нельзя его снова вырастить или обновить.

В народе говорят: телесная рана заживает. А рана на сердце не заживает, кровоточит всю жизнь. И это горе навсегда.

*Перевод с татарского А. Кузнецовой.*

# Хәтердә калмый шул барсы да

Юк, хәтердә калмый шул барсы да. Ул әле кечкенә иде бит. Ничә яшьтә булганын да хәтерләми. Тик шулай да хәтеренә мәңге сеңеп калган тормыш агымы юып китә алмаган хатирәләр саклана аның күңелендә. Әйе, ул хатирәләрне ул мәңге саклар, мәңге аның күңелендә көн яктылыгы шикелле үк сакланыр. Аның колак төбендә һаман бер көй, бер җыр, бер моң әле тын гына, әле көчәеп янгырый шикелле. Нинди җыр, нинди моң иде соң әле ул? Кайчан һәм кемнән ишеткән иде әле? Аларның барысын да хәтерли ул. Хәтта кайсы юлдын барганда җырланган җыр икәнен дә хәтерли.

Язгы айлар иде. Әллә ничек көннәр җәй якынлашкан саен җылынасы урында салкынлыгын югалтмады, киресенчә, ачы бураннары, салкын җилләре белән декабрь айларын хәтерләтте. Чалт аяз төннәрендә агачлар, мылтыктан аткан шикелле, шарт-шорт килделәр. Хәтта салкында кызынучылар да булды. Әнә шундый чалт аяз иртәләрнең берсендә Миргалине әтисе уятты:

– Улым, тор. Ат җигелгән, киен, – диде.

Миргали, ат турында ишетү белән җылы урыныннан сикереп торды. Күзләрен салкын су белән чылатып сөртте дә, йокы аралаш кызу гына киенеп, болдырга чыкты. Керфекләре арасыннан күктәге йолдызлар аңа бик зур булып тоелды, хәтта берсенең чаты Миргалиләрнең салам түбәле абзарларына тоташып торгандай тоелды. Әтисе уятмаган булса, андый гаҗәп йолдызны ул төшендә дә күрмәс иде, бәлки.

– Улым, чанага утыр, әтиеңә иптәш булырсың, – диде әнисе пышылдап кына.

Капка ачылды. Миргали әтисеннән аркасына артка табан карап утырды.

– Ат җиле хәтәр була, – диде әтисе.

Кузгалып киттеләр. Аларның артыннан еракка киткән саен

бер-берсенә якынлаша барган сыман ике тасма сузылды. Ай нурлары яктылыгында ул тасмалар Миргалиләрнең өйләреннән, авылларыннан сузылып, кайларга барып житәр икән? Кайда бара икән әтисе, кайда бара икән Миргали?

Бу вакытта аның иптәшләре нишләп уянсын ди, сорнай уйнаганын белми дә гырлыйлар инде алар. Ә Миргали әтисенең аркасына сөялеп, салкын таң жиленнән борынын яшерә-яшерә бара да бара. Әнә күпме юл үттеләр инде алар. Үрне менеп життеләр.

– Салкын түгелме, миңа сеныбрак утыр, – диде әтисе.

Үр төшкәндә күз алдыннан башта Миргалиләрнең өй түбәсе, аннары Мотай бабаларының кибет моржасы югалды. Мәчет манарасы, тирәк очлары озак кына күренеп торды. Тагын бераз баргач, авылны жир упкандай булды, ак кар белән капланган тигез жир генә җәелеп калды.

– Борынынны туңдырмадыңмы? Әтисе Миргалинең борынын сыйпап карады. Миргалинең бөтен маңгайлары, борыны, авыз һәм ияклəре әтисенең уч төбенә сыеп беттеләр. Шулай зур иде шул аның әтисенең куллары. Киндердән тегелгән тышлам бияләй кебек зур булса да, ул куллар Миргалине рәхәтләндереп, жылытып, көчләндереп, үстереп жибәрә шул.

Кола бия салмак кына атлап юрта да юрта. Әтисе белән ат бер-берсен күптән аңлашкангадырмы ашыкмыйлар; ат куараланып чапмый, Хафиз абзый киерелеп сукмырмый. Ара-тирә дилбегәсен кагып: «Әйдә, биякәй, на, малкай», – дигән тавышы гына ишетелеп кала.

Берәм-сәрәм агач куаклары очрый башлады. Әнә тегендә, уң якта, Хатип абзыйларның кое баганасы шикелле икегә аерылып үскән биек чыршы күренде. Авыз эченнән генә сызгырып барды-барды да әтисе, шыгырт-шыгырт итеп салмак кына баскан атка яраклашырга тырышыпмы, сузып жибәрде:

Һавада йолдыз ничәдер,
Санаган-лай саен күчәдер...

Өченче юлын авыз эченнән генә көйләде, соңгы юлын үзәк өзгеч әрнү белән төгәлләп куйды:

Гомеркәем заяга кичәдер.

Күрсенде дә, тагын авыз эченнән генә шул ук җырның көен көйләде. Миргалинең күз кабаклары авыраеп киткәндәй булды. Ул керфекләрен күпме аерырга тырышса да булдыра алмады, борын очын апасыннан калган сырма якасына төрәп, татлы йокыга талды.

– Улым, килеп җиттек.

Әтисенең тавышын ишетеп, Миргали уянып китсә, гаҗәпләнеп калды. Ни арада әтисенең алдына менеп утырган, ни арада авылга килеп җиткәннәр? Тан да ярылып, яктырып беткән. Юк, өйләренә кайтмаганнар икән лабаса! Кайсы авыл соң бу? Кар белән капланган өй түбәләрен, бәс сарган агачларны карап чыкты да, үз авыллары түгеллегенә тәмам ышанды Миргали.

– Вәчилей Чтапаныч белән күреш, улым, күреш, – дип кыстады әтисе.

Миргали кыенсынып кына кулын сузды.

– Бик әйбәт, молодец! Смена бар, бик әйбәт!

Василий Степанович Миргалиләрне үзләренең өйләренә алып керде. Миргали, әле әтисенә, әле Василий Степановичка карап алды. Әтисе тар гына түгәрәк сакаллы, күрешү шатлыгыннанмы күзләрен чылт-чылт йомып көлә, елмая. Елмайганда мангаендагы җыерчыклар тагын да ишәеп, тирәнәебрәк күренәләр. Ә Василий Степановичның сакалы куе, бөдрә, бөтен чигәсен, яңакларын, ияген каплап тора. Авызы да чак кына күренә. Авызын зур итеп ачып, энҗе кебек ап-ак тешләренең барысын да күрсәтеп көлә.

Чәй эчтеләр. Василий Степанович Миргалинең башыннан сыйпый-сыйпый кыстады.

– Аша, аша, зур үсәрсең! Чәй тундырмый???

Миргали әтисенә карап ала да, пары чыгып торган яшел кружкада чәйне суыра. Тик әтисенең Василий Степанович белән нәрсә турында сөйләшкәннәрен генә аңламый.

– Вот молодец! – дип Василий Степанович Миргалинең башыннан сыйпап куя. Үзе һаман Миргалинең әтисе белән сөйләшә.

# Аклар улын үтергән ата-ана кайгысы

– И, Аллакаем, үләм, үлә-әм, ничек түзмәк кирәк бу хәлгә. И балам, балакаем, балакачкаем минем. Шушы яшендә гомереңне кистеләр бит явыз дошманнар, башлары беткереләр. И, Аллам, ничекләр итеп түзәргә. Уф, йөрәккәем, уф. Нәрсәләр генә эшлим икән. Бала-а-ам, балакаем минем.

Ананың кайнар күз яшьләре борын буйлап тәгәри, авыз читләрен үтеп, ияклләренә тәгәри. Ул газиз улының хәрәкәтсез, суынып калган, ак күлмәгенә кызыл, әле кибеп бетәргә дә өлгермәгән кып-кызыл канга манчылган ак күлмәгенә каплана, маңгай-битләреннән үбә-үбә такмаклый:

– Мин сине шушы газапларны күрү өчен тудырдым мени? И Алла, ныгып кеше булгач кына... Ачы да соң үлем хәсрәтләре. Синең өчен үзем генә үлсәмче! Я Ходай, ник доганнан мәхрүм иттең безне! Ник үлемнән саклап калмадың минем газиз улымны. Ниләр генә эшлим, нәрсә генә кылыйм. И бәхетсез башларым.

Идиятулла абзый, мыштым гына күз яшьләрен сөртеп, карчыгын юатырга маташты. Аның таза, мәһабәт гәүдәсе кечерәеп, куырылып калган иде. Ул карчыгының иңбашына үзенең авыр кулларын салды.

– Елама, карчык, елама. Бетермә үзеңне. Нишләмәк кирәк. Ходайның тәкъдире шундый булгач... Аның тавышы бер көчәя, бер әкренәя, кайчак бөтенләй югалып кала. Аннары ул пышылдый, ишетелер-ишетелмәс кенә шыңшыган хәлдә.

– Я рабби Ходаем. Бар икән күрәселәребез, афәт күргәнче гүр иясе булуың артык. Дошманнар, кабәхәтләр.

Күршесе Хафизжан, тотлыга-тотлыга бу авыр хәсрәттән хәлсезләнгән авылдашларына эндәште.

– Күршекәйләрем, туганкайларым, үз-үзегезне бетермәгез,

үлгән артыннан үлеп булмый. Нишлисең бит, күрәчәкне күрмичә, кереп булмый гүрләргә, дигәннәр борынгылар. Аннары сонлап та барабыз... Аларның яңадан килүләре дә ихтимал...

Чыннан да, кояш үзенең гаять зур бишегенә кереп йокыга талган. Зәңгәр күктә йолдызлар җемелди. Офыкта кояш кызыллыгы сыекланып караңгылыкка әйләнә бара иде.

– Акларның әйләнеп килүләре ихтимал, килүләре ихтимал, ихтимал...

Бу сүзләр башта аның колагына йомшак кына, кайдадыр кое төбеннән ишетелгән пышылдау гына булып тоелды, аннары ул көчәя төште. Ул тавыш көчәйгәннән-көчәя барып, колакларны ярып керде һәм башны миңгерәтеп, урталай ярып үтте дә, җыелган халыкның көчле тавышы булып яңгырады.

– Акларның әйләнеп килүләре... Акларның килүләре... Акларның...

Идиятның үле гәүдәсен җайлап кына саклык белән печән өстенә салдылар. Юк, үлмәгән икән, йоклап кына киткән. Менә-менә сикереп торыр да, бөкләгән аяклары өстенә утырган хәлдә дилбегәне кулларына алып, көр тавышы белән атларны куалар. Аның яратып әйтә торган сүзләре һавада тирбәлеп торыр:

– На, малкай, на...

# Счастье

Моя собеседница – уважаемая односельчанка Назифа апа Шакирова. Седеющие волосы лишь придают красоту ее возрасту, выступают свидетелями событий ее жизни. Человек с чистым сердцем, уважительная к людям, Назифа апа живет, радуясь успехам детей и своих односельчан, с коими она всю жизнь жила дружно, в ладу, стараясь по мере сил помогать, как кровным родственникам. Живет, тесно общаясь с женой брата Рашидой апа, своей сверстницей, из молодых – с Данией Зайдуллиной, Розой Карамовой и еще многими другими. Она уважаема и как остабикэ (знаток основ исламской религии), и дети, и родственники, и односельчане часто приглашают ее на чаепитие.

Детство Назифы апа было не из легких. Она родилась 28 декабря 1916 года в деревне Карманово, в семье Мингазетдина, сына Габдулхалика, и Насимы. В три года Назифа осталась без отца. Через несколько лет мать вышла замуж за другого. Когда жили в д. Янтык (ныне Новый Артаул), Назифа пошла в первый класс.

В ее памяти сохранилось воспоминание об одном событии.

– Когда в 1924 году умер Ленин, наша учительница, тетя Газиза, плача и нахваливая его, рассказала о нем. Мы в слезах пришли домой. «Дочка, почему плачешь?» – спросили дома. «Умер очень хороший дед, поэтому плачу», – ответила я.

Горе всегда ходит по головам людей, а не по кронам деревьев. Неожиданно в 1932 году мать оставила этот светлый мир. А вскоре отчим привел домой молодую жену. Она была очень умной, красивой женщиной. Так как у меня не осталось ни своего отца, ни матери, меня вернули в деревню Бадряшево в дом деда со стороны матери Фазыла Мухаметшина.

– Он, земля ему пухом, был ласков со мной, – вспоминает Назифа апа. – Уже тогда, только-только окончив первый класс, верхом на лошади вышла на боронование. В семье не было мальчиков, поэтому мне с малых лет пришлось работать с лошадьми. Три года ходила на боронование».

Ранняя смерть родителей, сиротство, тяжелая работа с малых лет – все это помогло глубже понимать эту жизнь, сочувствовать другим.

В том же 1932 году Назифу апа приняли на работу в сельский Совет делопроизводителем. Затем работала в колхозе «Учкун» (д. Новый Артаул) учетчицей. Как тут не заметишь работящую, красивую, крепкую, старательную девушку? Ее сосватали за такого же работящего парня Мухаматнура Шакирова из деревни Истяк. В 1934 году началась для нее новая – семейная жизнь.

Молодая сноха сразу же приступила к работе в колхозе «Удар» (д. Истяк). И все время на поле. Когда бригадир второй бригады колхоза Хади абый Давлетшин сказал: «Сноха, иди на ферму, запрягай лошадь, будем вывозить навоз на поле», – она не отказалась. Конюхи Шаракай абый и Закир абый, ухмыляясь, велели ей самой запрячь лошадь, сказав коротко: «Дочка, сбруи там, в стойле, лошадь в загоне, запряжешь сама». Она запрягла лошадь и выехала в поле. «Вот это сноха, вот это да!» – восхищались конюхи. Оказывается, они решили испытать Назифу, сумеет ли, мол, запрячь лошадь. Но она работала с лошадьми с малых лет, поэтому не испытывала трудностей в этой мужской работе.

В те времена народ любил и умел работать. А все работы выполнялись или вручную, или с помощью лошадей. Истякское поле полностью пололи вручную. Тех, кто хорошо трудился, умели чествовать. А бригадирам Хади Давлетшину, Сулейману Зайдуллину даже показали с высоты птичьего полета их родные места. С самолета. Все еще в памяти, как они с восторгом и удивлением рассказывали, что дома с неба кажутся спичечными коробками. Бурлила вся деревня, наблюдая, как летит самолет.

Старательный труд всегда дает хорошие результаты. Перед войной хлеба очень уродились, за каждый трудодень давали по 7 килограммов 800 граммов хлеба, к каждому дому хлеб подвозили «красным обозом». Колхоз выделял даже мед. Были овощные, плодово-ягодные сады, которые приносили колхозу не только деньги, но и были просто красивы. А теперь эти места превратились в свалку, – говорит она.

В деревне были и свои изобретатели. Запрудив речку Каймашу, построили мельницу. С помощью воды и молотили, и веяли зерно. Все это придумал и сделал своими золотыми руками односельчанин Фатих Насибуллин.

С мужем Мухаматнуром Назифа апа прожила 56 лет, вырастили они пятерых сыновей, двух дочерей. Мухаматнура, ветерана войны и труда, в колхозе уважали. Нынче в сентябре исполняется 10 лет, как он оставил этот мир. Сын Борис привез из Сибири и посадил на его могиле несколько кедров. Сейчас они прижились, поднимаются в рост.

Дети Назифы апа и Мухаматнура абый, как и родители, выросли умными, всегда готовы прийти на помощь. В школе учились старательно, большинство получили высшее образование. Когда готовились к проведению 80-летнего юбилея школы, главный инженер транспортного цеха НГДУ «Краснохолмскнефть» Фарит Шакиров и инженер-строитель элеватора Ульфат Шакиров помогли и транспортом, и материалами, и рабочей силой.

У Назифы апа есть 16 внуков, 11 правнуков. Она радуется жизни, возносит хвалу кормящей нас земле, красоте лесов и полей. Верит, что все наладится, лишь бы войны не было. Назифа апа сведуща и в истории деревни, и в религии, читает баиты, мунажаты. И снохи, и внуки любят и уважают ее, почитают, то и дело приезжают в родной дом. Ежегодно, собравшись все вместе, отмечают ее день рождения. Да, она достойна такого глубокого уважения, почитания. И счастлива этим.

# Җыр өйрәтте безне хөр яшәргә

Бөек Җиңүнең 56 еллыгын билгеләгәндә, без кабат-кабат үткәннәргә әйләнеп кайтабыз. Фронт һәм тыл бер булып яшәде, эшләде һәм көрәште. Бөтен ил йөрәге бер булып, бергә типте.

Тормыш никадәр генә авыр булмасын, халык физик хезмәтне җыр, музыка белән бәйләде. Күмәк хезмәт үзенең оста гармунчыларын, җырчыларын, биючеләрен һәм шагыйрь-мәзәкчеләрен, тагын әллә нинди осталарын тудырды. Иң мөһиме, халык өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелеп, кулыннан эшен ташламады, сыгылып төшмәде, башын имәде. Ачлы-туклы, ярым-ялангач халкымның көне-төне бар көчен биреп, тырышып эшләве, кайгы-сагышларга түзүенә һаман да булса хәйрән калып, сокланып һәм гаҗәпләнеп яшим. Һәр өй саен ничәмә бала, аларны туйдырырга, киендерергә, укытырга, бәләкәй чана белән алып кайткан утынны, саламны, кара әремне ягып, өйне җылытырга, ризык пешерергә, хөкүмәт салымнарын түләргә, кара кайгылы хатларны укып, буыла-буыла үксергә һәм тагын эшкә тотынырга ничек көч тапты икән авылдашларым!

Илнең, Кызыл Армиянең, халыклар дуслыгының көченә, куәтенә, бернинди дошман җиңә алмаслыгына ышана иде халкым.

Әтиләре сугышка киткәндә, улларына гармуннарын мирас итеп истәлеккә калдырдылар. Егетләр гармунга кушылып җырлап, урам әйләнде, саф сөю билгесе итеп кызлар бүләк иткән кулъяулыкларын болгый-болгый сугышка, күбесе бәхилләшеп мәңгелеккә китте. Күңелләргә мәңгелек моң салып китте. Колакларымда һаман әле шул еллардагы җыр-моң яңгырап тора:

Урак урган җирләрем,
Печән чапкан җирләрем.
Күк чәчкәдәй күкрәп калды
Туган-үскән илләрем.

Сугыш елларында күпме җырлар, шигырьләр, бәетләр иҗат ителде. Игътибар белән сандык төпләренә күз салыгыз, бәлки, шунда сугыш елларында язылган хатлар, ядкарь дәфтәрләре, фоторәсемнәр сакланадыр. Буыннарны буын белән тоташтыручы кадерле хәзинәләр бит алар! Шул язмаларда яшьләрнең күңел сафлыгы, җиңүгә иксез-чиксез ышану, кайнар мәхәббәтләре, киләчәк тыныч тормыш турындагы якты хыяллары чагыла. Аларда тамчы да төшенкелек, бөртек тә икеләнү, курку юк, фәкать Туган илебезнең җиңәчәгенә, изгелекнең вәхшилектән өстенлегенә иксез-чиксез инану гына бар.

Кулымдагы балдагымның
Исеме Самания.
Иң кадерле әткәемнән
Аерды Германия.

Бу җыр нәкъ Истәк авылында туды, шунда җырланды.

Сугыш елларында иҗат ителгән җырларның иң күпчелеге «Кулымдагы балдагымның...» яисә «Кулымдагы йөзегемнең...» дип башланып китә дә, аннары җыр чыгаручы үзе белгән кадерле кешеләренең исемнәрен атый. Бу җырда аталган Самания кем соң ул? Бүген 92 яшен тутырган Самания апа – эшсөяр, бик абруйлы, мөлаем йөзле, җор сүзле минем кадерле күршем ул.

Самания апаның ире Сөләйман Зәйдулла улы Зәйдуллин да, авылдашлары белән бергә 1942 елның 14 февралендә сугышка китә. Моңа кадәр ул авыл Советы рәисе булып эшли иде. Аны Ленинград фронтына җибәрәләр. «Ленинградны оборонялаган өчен» медале белән бүләкләнгән. 1942 елның ахырларында Сөләйман аганың һәлак булуы хакында хәбәр килә. Өйдә елаш, кайгы. Самания апа иренең, мөселман йоласы буенча, җидесен, кырыгын үткәрә. 1944 елның көзендә... иренең

үлүе турында аңа тагын хат тапшыралар. Күрше генә булгач, без аның уллары Зикаф, Рамузлар белән бергә уйнап, эшләп үстек, дус, тату яшәдек. Һәм яшибез. Шул көннәрдә арадан кемдер шушы җырны чыгарды да инде.

Малайларның өметләре өзелми, ничек тә этиләрен кайтарасылары килә. Инде нишләргә?

Шулай бервакыт, кич, караңгы төшкәч, аулак өйдә, гөлбәчкә (мич белән стена аралыгы) кереп, чуен табага кәгазь ваклап салдык та, ут төртеп яндырып, мич стенасы янына китереп карап тора башладык. Ни гаҗәп, күп көттермәде, стенада кавалеристлар кылычларын болгап чаба башладылар, алар арасында дусларымның этисе Сөләйман абзый да күренеп кала кебек.

– Әнә, әнә эткәй! – диләр малайлар, сөенешеп. – Болай булгач, ул исән, эткәебез кайта, кайтачак!

Безгә ул чакта нибары 6-10 яшь иде. Чыннан да Сөләйман абзый, гаиләсен шатландырып, 1947 елда исән-сау кайтып төште һәм Самания апа белән бик тату яшәп, сигез бала тәрбияләп үстерделәр.

# Әсирлектә

1941 ел. Әгъләм Афзалтдин улы Әхтәмовны Истәк авыл Советына чакырттылар. Ул вакытта җирле Советның рәисе булып Сөләйман Зәйдуллин эшли иде. Исәнләшеп, күрешкәч, утырырга урын тәкъдим итеп, вакытны сузып тормады:

– Фронтта хәлнең көннән-көн кискенләшә барганын үзегез дә беләсез инде, – диде ул. – Кешеләр, транспорт, корал җитми. Безнең авыл Советына караган авыллардан 1917-1918 елгыларны җыеп, фронтка озатырга кушылды. Аеруча шоферлар, тракторчылар кирәк.

Сугыш! Коточкыч кан коеш, үлем, җимереклек. Фаҗига...

«Басуда эшләп йөргән җиреннән тракторчыларны да алып җибәргәч, фронтта эшләр шәп түгел инде», – дип уйлады Әгъләм Афзалтдин улы, өйгә кайтканда.

Дөрес, армия тормышы белән таныш иде инде ул. 1938 елның көзендә аны армиягә алдылар. Хабаровскидан ерак түгел авиачасть бар иде. Шунда хезмәт итте. 1940 елның ноябрендә авылга кайтты.

– Иске кием белән кайттык. Яна хәрби киемнәрне салдырып алып калдылар. Кешегә күренергә дә оят, – дип искә ала ветеран. – Мөгаен, сугыш башланырын сизенгәннәрдер.

Шул ук елны ул Янавыл МТСына авылдашы Шабекәй Галим улы Хәсәнов белән тракторчылар курсына укырга керә.

Һәм менә тагын повестка. Әгъләм бүген повестка алып, иртәгә үк фронтка китәрмен, дип уйламаган иде. Әшен, атын кемгә тапшырырга?

Ат арбасына төялеп, юлга чыктылар. «Исән кайтыгыз, җиңү белән кайтыгыз!» – дип озатты аларны туганнары, авылдашлары.

1941 елның 7 июлендә вагонга төяп, фронтка озаттылар. Шул вагонда Истәк авылыннан Сәгыйть Харламов, Мәгъсүм Хайварин, Гаян Шуваров, Муллаҗан Исламгалиев, Гайли Хәертдинов һәм күрше Ахтиял, Көек, Бәнәбаш, Таш-Елга авылларыннан да

егетләр күп иде. Алар Истәк авыл Советында, беренчеләрдән булып, сугышка киттеләр. Истәктән Хатип Хәйдәров «ЧТЗ» тракторы белән алардан да алда китте. Мулланур Шакировны да үзенең «полуторка»сы белән фин сугышына озатканнар иде.

Мәскәүдән 60 км чамасы ераклыктагы Дмитриев шәһәренә китереп төшерделәр, аннары Ржевка алып киттеләр. Вагонда укытып, әйберен, коралын биреп бардылар. Анда ай чамасы өйрәтеп, Смоленскига алып килделәр. Сугышка керттеләр. И кырылды халык, и кырылды. Дөньяның бетүе шушыдыр инде, дип торасың.

Әгъләм Әхтәмов элемтәче булып хезмәт итә.

– Бер мәлне – Свердловскидан рус егетен, Уфадан татар егетен, өчебезне элемтә ялгарга чыгарып җибәрделәр. Искитмәле атыш. Ничек кирәк алай каршы блиндажга барып кердек. Элемтәне ялгадык, ләкин немецлар килеп басты.

Фашистлар безне, машинага төяп, Смоленскига алып киттеләр. Юл буеннан безнең әсирләр бара. Бер километр гына түгелдер – немецлар көнбатышка куып баралар. Ә безне, Смоленскига алып китеп, зур амбарга тутырдылар. Су юк. Кар ашыйбыз. Шулкадәр тамак корыды. Берничә көннән соң безне, поездга төяп, Шауляй шәһәренә китерделәр, анда унбиш көн тоттылар. Аннары, унбиш километр җәяү барганнан соң, берәүнең амбарына илтеп тыктылар. Меңнән артык кеше. Аэродром төзергә алып килгәннәр икән. Кыш көне җир казыттылар.

Баракның астын казып, тоннель ясап, йөзләгән кеше качты. Аннары баракны пыр туздырдылар. Ике мең кеше идек, кыш чыкканчы ике йөз кеше калдымы-юкмы. Ачлыктан, төрле авырулардан, тиф чиреннән, җәзалау, атудан һәркөнне дистәләгән кеше үлеп торды. Эш авыр. Төн җирне казыганда да кайберләребез үлеп тора. Бет. Күлмәкләрне таякка элеп эссе мичкә куябыз. Бетләр шыбыр-шыбыр коела. Бөтен кыш буена бер тапкыр апрель айларында мунча ягып кердек.

1943 елда бизгәк чире эләкте. 36 килограммга калган идем. Бер рус егете карады. Немецлардан калган ашны биреп ашата башлагач, чирләләр юнәя башладылар.

Каунаска күчерделәр. Аннары Германиягә алып китәләр иде,

Каунастан чыгып та житә алмадык, совет гаскәрләре килеп житте. Безне танкистлар коткарды. Ә тиздән сугышка, алгы сызыкка алып бардылар. Аннары безне фронттан алып, эшелоннорга төяп Калининга алып килделәр. Резина әйберләре заводына эшкә куштылар. Анда да конвой астында йөрдек. 1945 елның июнендә генә конвой бетерелде. 1946 елны отпускага да кайтып әйләндем. 1947 елда заводта слесарь-тракторчы булып эшләдем.

1950 елдан колхозның кырчылык бригадиры, ике ел жиләк-жимеш бакчасы бригадиры. 1966 елдан мәктәпнең хужалык мөдире, 1980 елнын февраленнән пенсиядә. Әтисе Афзалтдин да сугыштан (хезмәт армиясендә була) исән кайтты. Ә менә 1923 елда туган Каниф энесенең генә гомере сугыш кырларында өзелеп калды, «билгесез югалды» дигән тоньк кәгазьгә язылган хәбәр генә кайтты.

Кайда гына булмасын, Әгъләм Афзалтдин улы эшенә намус белән карады, тырышып, жанын-тәнен биреп эшләде. Бригадир булып эшләгән елларында югары уңыш алганы өчен ике тапкыр Уфага, 1953 елда Мәскәүгә күргәзмәгә (ВДНХ) барды, II дәрәжә Бөек Ватан сугышы ордены, тугыз медале бар.

Әгъләм ага тормыш иптәше Мәдәния белән биш бала тәрбияләп үстерделәр. Әйбәт тәрбия бирделәр, балалары югары һәм махсус урта белем алдылар. Аларның ун оныгы, өч балаларының баласы бар. Барысы да зур әткәй, зур әнкәй дип кенә торалар, һәрберсе кадерле, хөрмәтле аларны, һәр яктан да үрнәк гаилә бу. Тәртип, чисталык капка төбеннән үк башланган. Ишек алларында да жыйнаклык. Ә өй яны бакчасында алмагачлар, баланнар үсә. Бал кортлары умарталары да бакчага ямь өсти.

Әйе, сугыш һәм хезмәт ветераны Әгъләм Афзалтдин улы Әхтәмов үзенең хәләл жефете Мәдәния белән пар күгәрчендәй гөрләшеп пөхтә, чиста һәм жылы өйдә бәхетле яшиләр.

– Әйе, рәхәт дөньяга чыктык, еллар гына имин торсын, – ди ветеран.

# Самый вкусный хлеб

Время неуловимо отделяет нас от военного лихолетья. Но незабываемы суровые испытания тех лет, которые вынесли люди, глубоко веря в победу над ненавистным врагом. Не жалея сил и времени, не жалея себя, люди трудились в тылу днем и ночью, несмотря на голод и физическое изнеможение.

Я помню те незабываемые дни, когда односельчане от мала до велика выходили на сенокос. Часть мальчиков-«джигитов» старше 12-13 лет вместе с женщинами с раннего утра до поздней ночи косили сено, заменив своих отцов и старших братьев, которые воевали на фронте. Каждый знал, что сено нужно не только колхозу. Ведь часть его отправляли на фронт. Все чувствовали, что каждый вносит свой вклад в Победу.

Старики учили косить сено и юношей, и девушек, правили косы. Полушутя, полувсерьез подзадоривали:

– Эй, пятки береги!

– Быстрей, на пятки наступлю!

– Коси так, чтобы по подмышкам ветер гулял!

– Не мешкай, шевелись!

– Кому оставляешь сено под покосом?! Нехорошо...

На другом поле шла уборка сена. Здесь также руководили деревенские старики Шамсутдин Фазлиахметов, Закир Шуваров, Акмалтдин Гарипов и другие. Работали и дети. Возили копны на лошадях. Работали с большим желанием и усердием.

Наступают сумерки. Поставлены высокие и красивые скирды. Старики отпускают хозяек домой на дойку коров, с оставшимися продолжают скирдовать сено.

– Айда, ребята, повеселей, тучи сгущаются, приближается гроза. Давайте быстрее.

Дети, а это были на самом деле дети, трудились как взрослые, старательно и упорно.

На быках собирали веточные корма, липовые веники, осенью возили снопы. Ох, как трудно было управлять этими быками! Твердо-

лобые, непослушные, но в конце концов примирившиеся с несвойственными для себя обязанностями.

А как приятно было обедать вместе со всей деревней во время сенокоса из общего большого котла в самом красивом месте — на берегу реки, где варили суп с мясом, где вкусно пахло новоиспеченным ржаным хлебом.

— Колхозные поля тоже напоминали поле сражений, только здесь не было стрельбы. Лозунг Родины «Все для фронта, все для Победы!» стал каждодневным девизом всех тружеников села.

С тех времен прошло 37 лет, но старейший механизатор Сагит Харламов с благодарностью вспоминает взаимопомощь механизаторов. Может быть, тогдашний бригадир Рабакской бригады Исхак Исламов уже забыл, как он дал генератор Сагиту и тем самым выручил его, появилась возможность работать ночью. Да, хорошее не забывается...

23 года жизни посвятил труду механизатора Сагит Харламов. Не отставала от своего мужа и Бибизиган-апа. Каждый участок колхозного производства для нее был знаком: жала, косила, очищала зерно, ухаживала за скотом, удобряла поля. Одновременно воспитывала семерых своих и двух осиротевших детей. Материнское тепло делила всем поровну. Четверо их них — Хасина, Фануза, Василя, Виния — работают в своем родном колхозе имени М. Горького животноводами, добиваются хороших показателей в труде. Насима участвует на разных работах, Финзиля выбрала специальность строителя, Гульсум стала поваром.

Семья Харламовых — одна из уважаемых в деревне. Да, нельзя не уважать таких. Уважение завоевывалось всю жизнь, каждодневным упорным трудом, отношением к окружающим.

Накануне юбилея республики родные, близкие и дети отметили 70-летие отца, дедушки Сагит-ага Харламова и пятидесятилетие их совместной жизни. Радостно улыбаясь, он говорил: «Мы вырастили Башкирию, а нас вырастил Башкортостан!»

# Ради Победы

Лето. С дедом Гафаром сидим в его саду. Рядом шелестят листья калины, недалеко – яблони, кустарники смородины, крыжовника, малины. Созрела виктория. Тут же грядки помидоров, огурцов. Там зеленеет ботвой картофель. Он весь в цвету.

Любил старик землю, любил крепко, самозабвенно. Уходу за ней посвящал свое свободное время. Работать тоже умел. Вкладывал всю душу.

– Это счастье, когда можешь трудиться на земле, – часто повторял он.

Да, нельзя не согласиться с этим уважаемым, много повидавшим за свои семьдесят лет человеком.

Сегодня у него хорошее настроение. На исхудалом лице играет приятная улыбка, сияют глаза. Мне давно хотелось расспросить о его жизненном пути, но раньше как-то смелости не хватало. Сегодня наш разговор нечаянно пошел по этому руслу.

Гафар Абдулкарамович Абдулкарамов родился в селе Старый Курдым Татышлинского района. Когда началась Великая Отечественная война, на фронт ушел из Тибельского лесоучастка, расположенного недалеко от деревни Хамитово. Здесь из березовых корней заготавливали материалы для деревянных частей винтовок. Он был возчиком. А вот что рассказал он мне о своем солдатском пути на этой последней встрече, что запало мне в душу.

– Пришли в райвоенкомат около 70 человек. Меня хотели определить в трудовую армию. Но я наотрез отказался. «Отправьте меня только в действующую армию, на фронт, на передовую», – настаивал на своем. С трудом, но своего добился. Это было 2 марта 1942 года.

Г. Абдулкарамов воевал до конца войны. Сражался на Воронежском фронте. Ранен был несколько раз. Он рассказывал мне эпизоды из боев, в которых участвовал, а я запоминал.

– Шли бои на Украинской земле, за город Харьков. Но я туда не дошел. Ранило меня под Белгородом в Курской области. Мы встретили немцев у местечка Шебекино. Здесь произошла схватка. Слу-

жил я в роте связи. Когда был ранен, свой пост не бросил, но заставили идти в медсанбат. Госпиталя поблизости не было, раненых распределяли по домам в деревне. Еду готовила раненым, обычно на 2-3 человека, хозяйка дома. Я еле добрался до крайнего дома, меня положили в постель. Спал целые сутки, даже боль в ранах не повлияла. Когда шли бои, спали урывками. Ранен был в ногу, выше колен. Один осколок врачи удалили, а два осколка так и остались в моем теле, которые мешают и поныне.

Во второй раз вражеский автоматчик ранил в левую руку. Я полз к траншеям немцев, чтобы сбросить гранату.

Потом стал пулеметчиком. Опять нашла пуля. Затем автоматчиком. На этот раз сразу три пули пробили руку, раздробили кости. Лежу в госпитале. Кость не заживает. Уже собрались ампутировать. В это время ходила врачебно-контрольная комиссия, и она запретила делать ампутацию (рука после выздоровления стала короче, но рука есть рука).

Из Белгорода нас повезли в другой госпиталь. Ехали целую ночь. Было холодно, топили печурку. К утру, когда светало, мы подъехали. Госпиталь находился примерно в тридцати километрах от станции в городе Мичуринске. На станции нас встретили не повозки и не машины, а женщины с санями. Сами голодные, слабые, но тянули. Если вспомню, глаза наполняются слезами. Милые наши женщины! И думал, до чего народ старался ради победы.

В октябре 1945 года приехал с войны. Вот с этих пор живу в Янауле. Очень нравится мне поселок. Люблю свой сад, огород. Все, что окружает нас.

Дед Гафар немного замолчал и повторил, тяжело вздохнув: «До чего же народ старался ради победы. И отстоял землю-матушку».

Зашумели, загудели деревья, посаженные им, повторяя слова ветерана, старого воина: «Ради нас, ради жизни!»

...Это была моя последняя встреча с добрым человеком, отстоявшим землю и оставившим нам после себя мирную жизнь.

# Җиңү тантанасы

Үзешчән сәнгать беркайчан да тынып тормады һәм тормый да. Сугышка киткән егетләрне сәхнәдә кызлар һәм малайлар алыштырды. Сәхнәдә парлап биергә егетләр булмагач, кызлар беренче тапкыр чалбар, башларына кепка яки бүрек киделәр. Авылда малайлар бигрәк ваклар иде шул әле. Фронттагы сөйгән егетләреннән энеләренә карап соклана һәм аркаларыннан шапылдатып сөяләр иде кызлар.

Үткән елда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 55 ел тулуга багышланган «Җиңү салюты-55» район үзешчән сәнгать фестивале моңа кадәр күрелмәгән югарылыкта үтте, хәзерге буынның ата-аналары традицияләренә тугрылыклы булуын күрсәтте һәм чын мәгънәсендә бөтен халык бәйрәменә әйләнгән иде.

...1945 елның 9 маенда Истәк авылы чәчүчеләренә шатлыклы хәбәрне атка атланып чабып килгән малайлар китерә. Шунда сугыштан яраланып кайткан, хәзер звеновод булып эшләгән Мөхәммәтнур Шакиров, дәртләнеп китеп:

– Бир әле, Шәмсениса, яулыгыңны, яулыгың кызыл икән. Мондый бөек Җиңү Бәйрәмен кызыл әләм белән каршылыйк! – дигәч, агач сапка бәйләп, калку җиргә кадап куя. Халык шатлана, күз яшьләренә чыланып, бәйрәм итә.

Ә без, малайлар, җыелышып, Яңавылга киттек. Тимер юл буенда – халык! Поездлар туктаган. Җиңү тантанасын хәбәр итеп, гудоклар яңгырый. Вагоннарның ишек-тәрәзәләре иңенә ачык. Күктә аллы-гөлле ракеталар аталар. Яшел гимнастерка кигән хәрбиләрнең күкрәгендә орден, медальләр, май кояшында ялтырап, күзләрне чагылдыра. Ул кочаклашу, үбешү, елашу. Халык күнелле көчле язгы ташкынны хәтерләтә иде. Бу күренешне сүз белән генә аңлату мөмкин түгелдер. Моңа кадәр суны бүлеп торган буаны ерып җибәргән шикелле, халык күңеле иксез-чиксез киңлекләргә, зәңгәр күкләргә атылды,бәхетле йөзләр нур булып балкыды. Гармун моңнары яңгырый, җырлыйлар, бииләр, сызгырып кул чабалар.

Үзеннән-үзе зур концерт башланып китте һәм бик озак дәвам итте. Ул бәйрәм тукталмас, өченче меңъеллыкта да дәвам итәр әле!

# Сәрия

Сугыштан соңгы еллар иде.

Кыш уртасы. Чалт аяз төн. Тынлык. Аз гына да җил исми. Күкнең мәңгелек күзләре – йолдызлар балкып яна. Ай җиргә көмеш нурларын сибә. Агачларны бәс сырган, әйтерсең лә алар ап-ак чәчәкләргә күмелгән.

Авыл клубыннан урамга яшьләр килеп чыкты. Тынлык булмаган да диярсең. Күптән түгел генә сугыштан кайткан егет бармакларын гармун басмакларыннан йөгертеп үтте дә иптәшләренә эндәште.

– Җырлап урам әйләнмибезме? Кайсы очтан башлыйбыз? Үзебезнең югары очтанмы?

Егетләр бишкуллап риза. Аларга кайсы очтан булуы барыбер, тик гармун гына уйнасын.

– «Сәрияне» уйна әле, Мирзахан абый, – диде арадан берсе, Мирзахан ялындырып тормады. Менә гармунның сихри авазлары яңгырады.

Йорттан-йортка, агачтан-агачка сугылып гармун моңы еракларга таралды. Кемдер җырлап җибәрде, башкалары аны дәррәү күтәреп алды:

Ике матур суга бара, Сәрия,

Җем-җем итә чиләге, Сәрия...

Гармун күрекләре соң чиккәчә тартыла, моңнары күңелләрне җилкендереп җибәрә. Гармунга кушылып, аяк астында кар шыгырдый. Җырның соңгы сүзләренә аеруча басым ясап җырладылар:

Без яшьләрне яратабыз

Яшьтән эшләп үскәнен.

Гармун, соңгы аккордларын биреп, тынып калды.

– Их, яратам мин шушы җырны, егетләр. Сталинград сугышында да үзебезнең халык җырлары җиңүгә көч бирде миңа. Сезгә генә сер итеп әйтәм: кызым туса, Сәрия исемен кушачакмын, һәм авыз эченнән генә көйләп куйды:

Җир җиләген бик яратам, Сәрия,

Алсуланып пешкәнен, Сәрия...

Сугыштан күкрәгенә хәрби наградалар тагып кайткан лейтенант Нартдинов Истәк авылында клуб мөдире булып эшли иде ул көннәрдә. Вәгъдәсендә торды ул: кызларына Сәрия исеме куштылар.

# Сак-Сок

I

***(Г. Тукайга ияреп)***

1. Без ике малай
Туймадык уйнап,
Чыгар димәдек
Уеннан уймак.

2. Әйләндек кошка,
Әнкәй каргагач.
Очтык урманга,
Канат яралгач.

3. Урман эченә
Төшми яктылык,
Явызлык кылсаң,
Көтмә яхшылык.

4. Улый ач бүре,
Тавышы шомлы.
Арба эзеннән
Эчәбез суны.

5. Ябалак бугай,
Ачы сызгыра.
Агач башында
Бер кош кызына.

6. Елан шуышып,
Чыжылдап үтә.
Без йоклаганны
Күз йоммый көтә.

7. Коры ботаклар
Шартлап сыналар.
Төлкеләр арттан
Борын сузалар.

8. Куркыныч монда:
Гөрселди урман,
Карт имән ауды,
Йөз ел утырган.

9. Төн үткәрүе
Иң газаплысы.
Кая ул йокы,
Керфек какмыйсың.

10. Сандугач сайрый,
Күке кычкыра,
Бик сагындыра,
Елыйм еш кына.

11. Газиз әнкәбез,
Сагындык сине.
Ничек үткәрик
Без кара төнне.

12. Кайдадыр таулар
Ишелеп төшә.
Коточкыч шартлау
Колакны кисә.

13. Без һаман ялгыз,
Уртада таулар.
Менә алмыйбыз
Ташлары кайнар.

14. Тилмереп күпме
Яшәрбез икән.
– Әнкәй, әткәй, – дип
Дәшәрбезме икән.

15. – Сак! – дип кычкырам,
Ишетәсеңме?
Мине исән дип,
Хис итәсеңме?

16. Сак-Сок, Сак-Сок дип,
Яңгрый урман,
Чатырдый яшен,
Калтырап торам.

II

1. Таңда бер мәлне
Киттем сискәнеп,
Әнием-жаным
Килгән икән, дип.

2. Ишеттем сыман
Йомшак тавышын.
Әллә чын булды,
Әллә ялгыштым.

3. Тораташ сыман
Катып тыңладым,
Тавыш югалды,
Үкереп еладым.

4. Юк, әнә үзе,
Эзли ул безне.
Табар, табачак,
Аналар изге!

5. Ана беркайчан
Баласын жуймас.
Шаярган өчен,
Сәхрәгә кумас.

6. Якында гына
Түгәрәк алан.
Пешкәндер жиләк,
Жыеп ал тапсаң.

7. Чиләк тутырып,
Алып кайт жиләк.
Каклап куярсыз,
Кыш тәмле бигрәк.

8. Мин жыя алмыйм,
Елыйм да елыйм.
Кош канатына
Әйләнде кулым.

9. Әнкәй каргагач,
Әйләндек кошка.
Өйгә кайтмыйбыз,
Яшибез тышта.

10. Урман – безнең өй,
Көн үтә шунда.
Өшибез төнлә,
Мендәр юк монда.

11. Их, кайтыр идек
Жылы өйләргә.
Йоклыйсы килә
Йомшак мендәрдә.

12. Әнкәем сөеп
Уятыр иде.
Жиләкле чәен
Кайнатыр иде.

13. Ник эзләп килми,
Әти кадерлем.
Назлап сөйгәнен
Һаман хәтерлим.

14. Әти эзләсә,
Безне табачак.
Өйгә туп-туры
Алып кайтачак.

15. Әнием-жаным,
Без һаман исән.
Нишләр идек без,
Бер үбеп сөйсәң.

16. Яңгыр явармы,
Яшәртә икән.
Мәңге тилмереп,
Яшәргәме икән.

III

1. Урман һавасы –
Шифалы һава.
Күкне күкрәтеп,
Яңгырлар ява.

2. Урман һавасы –
Баллы, саф һава.
Сагынып саргайдык,
Аннан ни файда.
3. Әти жиккән ат
Тугайда уйный.
Безнең турында
Әти ни уйлый.
4. Әнинең елап
Яше кипкәндер.
Ник каргадым, дип
Газап чиккәндер.
5. Әткәем-бәгърем,
Якындасыңмы?
Улкайларыңны
Сагынасыңмы?
6. Туры атыңны
Иярләденме,
Газиз әнкәйне
Ияртмәденме?
7. Озатып калдымы
Ризалык биреп.
Теләкләр теләп,
Табып кайт, диеп.
8. Табарсың безне
Кошлар моңыннан.
Минут та тынмас
Урман жырыннан.
9. Тауларга кара:
Бер кош талпына.
– Кил, мин монда! – дип,
Улың чакыра.
10. Икенче улың
Таулар артында
Тукталма, әти,
Бар да бар шунда.
11. Башка кошлардан
Аера бел генә,
Кешедән туган
Кошлар без генә.
12. Бездә сезнең кан,
Акыл һәм шөгыль.
Безне табуы
Һич авыр түгел.
13. Чокыр-чакырлы
Урман юллары.
Якында гына
Бүре улады.
14. Әти килә, дип
Һаман түзикме,
Килмәсләр, диеп.
Өмет өзикме.
15. Әнкәем-бәгърем,
Зинһар, гафу ит.
Иң кадерлесе
Бергә яшәү бит.

**IV**

1. Кавказ таулары
Һай биек икән.
Түбәсендә кар,
Мәңгелек микән.
2.Иртә-кичләрен
Бүреләр улый.
Бүреләр түгел,
Кешеләр елый.
3. Без дә елыйбыз,
Һич түзәр хәл юк.
Мондый мәхшәрдән
Качар әмәл юк.
4. Ишеткән саен
Сугыш хәлләрен,
Чымырдап куя
Минем тәннәрем.

5. Ишеткәнем бар:
Җир жиде кат, дип.
Сугыш күрсәтте:
Бу тәгъбир хак бит.

6. Шаһитләре без
Канлы сугышның.
Җимерәләр бит
Матур тормышны.

7. Туган йортыннан
Халыклар купкан.
Котлары очып,
Сугыштан, уттан.

8. Тетрәнә җирләр,
Ярыла туплар.
Бу хәлне күрсәң,
Йөрәгең туктар.

9. Автомат тотып,
Кердек сугышка.
Мәет, дары исе
Капты сулышка.

10. Ит турагычта
Турыйлар анда,
Балакаем, дип
Тормыйлар монда.

11. И яшь җанкайлар,
Булдыгыз гаеп.
Мәсхәрәләнгән
Никадәр мәет.

12. Җир-ана чүгә,
Таулар ишелә,
Коточкыч афәт
Килде кешегә.

13. Күпме балалар
Калдылар ятим.
Чечня күгендә
Ялтырый яшен.

14. Юк, яшен түгел,
Урман, өй яна.
Авыл, шәһәрләр
Яна барысы да.

V

***(Чечня сугышы)***

1. Абый еракта.
Чечня җирендә.
Рәсеме килде
Хәрби киемдә.

2. Хаты бик кыска,
Ашыкты микән:
– Ант кабул иттек,
Чечняга китәм.

3. Ишеткәч, әни
Үксеп елады.
– Улым, бәгърем! – дип
Авыр сулады.

4. Әтием шулчак
Бик нык үзгәрде.
Яшьләнгән иде
Анын күзләре.

5. – Елама, карчык,
Сөрт күз яшеңне.
Минем дә йөрәк
Әрни, яшермим.

6. Сакла үзеңне,
Тыныч, сабыр бул.
Алла теләсә,
Исән кайтыр ул.

7. Озак, бик озак
Көттеләр хәбәр.
Нинди куаныч
Хат килсә әгәр!

8. Әнкәй-әткәбез
Калды тамактан.

Сагынып саргайдык,
Хат юк солдаттан.

9. Абыйны әни
Барып тапмакчы.
Чечня жиреннән
Алып кайтмакчы.

10. Әнкәйне ничек
Жибәрмәк кирәк.
Адашуы бар,
Ул-өйдә терәк.

11. Сүз берләштек без
Фәрит һәм Әдип
Әткәй, әнкәйгә
Тормаска әйтеп.

12. Алып кайтырбыз,
Абыйны табып.
Чечняга гына
Житик без барып.

13. Чечня жиренә
Китеп барабыз.
Белми дә калды
Ата-анабыз.

14. Абыйны эзләп
Йөргән чакта,
Алып киттеләр
Безне бер частька.

15. Танк өстенә
Утырып бардык.
Юлда жимерекләр,
Кораллы халык.

16. Командир сорый:
– Сез кемнәр? Кайдан?
Әллә төштегез
Тегеннән, айдан?

17. Йомышыгызны
Я, тынлап карыйк.
– Абыйны табып
Авылга кайтыйк.

18. Сугышлар тынгач,
Кайтырлар илгә.
Ул хәрби антын
Үти бу жирдә.

19. Солдат ашларын
Без дә ашадык.
Абыйны эзләп
Таба алмадык.

20. Киткәнгә ташлап
Өйне үкендек.
Әткәй, әнкәйдән
Гафу үтендек.

21. Ант иттек качып
Чыкмаска юлга.
Ата-ананы
Салмаска утка.

# Первый механизатор

Был сентябрь 1929 года. В дань уважения коллективному труду богатая уродилась гречиха. За околицей шумно работали колхозники – намолачивали первый урожай. Среди них – Бибизиган, одна из первых красавиц села. В ее руках так и играло молотило. Работает сноровисто. Прилипшие к лицу с сероватым оттенком пылинки будто придают особую, принадлежащую только ей красоту.

Чуть поодаль за быстрыми движениями своей любимой следит Сагит. Звонкий смех Бибизиган манит его к себе, зовет. До условленного времени осталось еще два дня. Скоро, очень скоро она будет его...

Вспоминая прошлое, супруги Харламовы с наслаждением говорят о тех памятных эпизодах полувековой давности. Пятьдесят лет! Как быстро летит время!

Поделили они все пополам: и счастливые минуты, и горести. Время словно испытывая их верность, преподносило все новые и новые испытания. Главное, что их объединяло, – оба любили труд. Трудились на зависть другим, трудились, наслаждаясь.

Когда в деревне началась коллективизация, двух лошадей и одну корову они первыми повели на ферму. Пахали, сеяли, убирали. Ударницей стала Бибизиган. Редко, кто мог поравняться с ней в трудовых состязаниях. Вырастили, будто из-под земли, снопы под ее серпом.

Тянуло молодого Сагита к технике. Правда, он этих «стальных коней», как тогда говорили люди в колхозе с восхищением о тракторах, не видел, но доходили слухи, что на полях деревни Рабак работают эти могучие машины.

Партийные и советские органы искали новые формы вовлечения крестьян в колхозы. Осуществляя мечту В. И. Ленина, рабочие отправляли селу тракторы. При Янаульской машинно-тракторной станции были открыты курсы. Правление

колхоза решило направить на эти курсы передовиков Сагита Харламова и Нургалия Арсланова.

В этот день 1932 года на селе был настоящий праздник. Сагит-ага Харламов вспоминает: «Вся деревня собралась посмотреть трактор. Толпа любопытных обступила новенький «ХТЗ», каждому хотелось потрогать, пощупать... Людям не верилось, что железная машина может работать. В этом году мы со своим напарником запахали межи, которые огораживали земельные участки единоличников. Это в какой-то степени была наша первая победа!»

Передавая нам трактор, директор МТС Хайрулла Каримов говорил: «Своей работой вы можете доказать преимущество коллективного хозяйства. Словом, от того, как вы будете работать, зависит судьба колхоза».

Приходилось «кочевать» по полям колхоза. Везде Сагит Харламов работал с присущей ему энергией. От зари до заката солнца он пахал, сеял. Вместо маломощных тракторов начали поступать «ЧТЗ». По тогдашним сравнениям эти гусеничные тракторы казались великанами. Теперь уже были необходимы более глубокие знания техники.

Члены правления единогласно решили послать на курсы в Уфу передового механизатора С. Харламова. Учился он прилежно, осваивая азы новой машины. Ведь ему предстояло передавать свои знания другим механизаторам.

В 1937 году его направляют в Рабакскую бригаду. Руководил бригадой признанный на весь район механизатор Байрам Исламов. В бригаде работали любящие технику механизаторы Гильфан Хаертдинов (из деревни Ахтиял), Шаракай Шаймартданов (Рабак), Муллый Ахметшин (Арлан). Интернациональная бригада механизаторов в этом году вырастила богатый урожай зерновых культур.

Росли, крепли колхозы. Люди теперь работали коллективно, земля оплачивала хорошим урожаем. Входила в колею крестьянская жизнь.

...Июль 1941 года. Мирную профессию механизаторы сме-

нили на военную – стали защитниками Родины. Сагит участвовал в сражениях за города Великие Луки, Смоленск. Получил контузию. После лечения его отправили в распоряжение военного комиссариата нашего района.

Снова любимая работа. Он возглавляет бригаду механизаторов в деревне Болтачево. Выбор не случайно пал на Сагита Харламова. Бригада считалась одной из отстающих из 14 бригад МТС. Бездействовали два «ЧТЗ» и один «У-2». Приходилось днем и ночью работать для фронта. Вожак бригады сумел организовать труд механизаторов так, что по итогам года она заняла второе место.

На вопрос, что им способствовало сделать такой скачок, Сагит-ага говорит:

– «Не спеши, мальчик, обязательно и тебе достанется. Проголодался, да? Потерпи малость. Ты ведь не один», – говорили повара. Пекли хлеб и варили суп на все село местные истинно народные повара и пекари – от меня им низкий поклон. Мы помним вас, дорогие женщины.

А замечали ли вы, проходя мимо хлебопекарен и хлебных магазинов, что теперь почти не чувствуется приятного запаха хлеба? Раньше, если где-то его пекли, душистый, приятный запах распространялся на всю деревню, своим ароматом возбуждая аппетит. «Почему же так?» – говорят мои односельчане. А может быть, причина в том, что мы стали работать спустя рукава, без романтики и жара сердца? Или живем в достатке?

*«Янаульские зори», № 54 от 9 мая 2002 г.*

# Играй, друг, на гармони

Никогда не забуду этого. Был август 1959 года. Солнечный, теплый, красивый день. Нет даже намека на ветер. Но настроение подавленное, в доме скорбь, потому что отец лежит на смертном одре. Все понимаем, что он тяжело болен, что это его последние минуты. Мучительные, горестные минуты. Эх, облегчить бы его положение хотя бы на некоторое время, как-то помочь. Особенно досадно, что видишь и знаешь, но ничего уже сделать нельзя.

Кажется, отцу немного полегчало, жестом позвал меня к себе.

– Сынок, что-то плохо мне, – сказал он шепотом, – иди, позови, пожалуйста, Гилимхана, пусть возьмет и гармошку.

Я побежал. Он оказался дома. Когда отец увидел нас на пороге, на его лице отразилось оживление, и он попросил дядю Гилимхана сыграть на гармошке. Гармонист играл долго. Дивной гармонией и волшебной силой прозвучали любимые мелодии отца, они проникали в самую глубину души, наворачивали слезы на глазах, уносили в глубокую пучину дум.

Отцу, кажется, стало легче, и он, взяв мою руку в свои, под звуки мелодии сказал, чуть дыша:

– Спасибо, сын. Прощайте. Мать не бросай, ухаживай за ней. А Гилимхану скажи, пусть не расстается с гармонью.

А гармонь играла и играла, разрывая душу... Так простился отец с жизнью. И словно заснул, тихо ушел из этого мира.

И именно в этот горестный день я глубоко, по-настоящему, бесповоротно поверил в чудодейственную силу гармони в руках дяди Гилимхана, не было конца моей благодарности гармонисту.

Этим гармонистом был мой двоюродный брат Гилимхан Шамсетдинович Фазлыев, родившийся 26 ноября 1929 года. Может быть, кому-то это не понравится. А кто-то и скажет, что хвалить своего родственника не пристало. Но я надеюсь, что односельчане, кто знает его и кто влюблен в его игру на гармони, простят меня. Вот уже около сорока лет люди несказанно восхищаются его талантом.

Вот уж природа не пожалела дарования.

У каждого дела есть свой мастер. Заболел – обращаешься к врачам, не горит свет – бежим к электромонтеру. Каждый старается помочь по своей специальности. Но вот как удовлетворить духовные запросы людей? Правда, сейчас много газет и журналов, есть телевизор, радио. Но человек не может и не хочет быть всегда наблюдателем со стороны, ему надо участвовать в этом процессе.

Если он гармонист, к тому же настоящий – играть будет не только тогда, когда этого своя душа просит, но и тогда, когда это нужно другим – для детей, для человека, лежащего на смертном одре. Есть люди, не умеющие ни петь, ни плясать, но и они влюблены в чарующую мелодию. Гармонист – это не узкая специальность, он дает душе человека неиссякаемую духовную пищу. Гармонист – страж нации, страж ее духовных богатств, языка, искусства, а также последователь и умножитель традиций народа. Послушаешь трели гармони – на душе становится чище, а жизнь легче. Вот этому великому делу наш односельчанин Гилимхан-ага отдал всего себя и бескорыстно служит народу, нации, воспитывает у людей самые светлые качества.

Дядя Гилимхан рос в многодетной семье. Четверо из семерых играли на гармони. Откуда же идет такая любовь?

– Играл и мой брат Тимерхан. Когда уезжал на фронт, сам играл, сам пел и не удержался от слез. Не вернулся с войны. Пусть земля будет ему пухом.

Раньше в деревне Истяк гармонистов было довольно много: Халиль Валиев (тоже не вернулся с войны), Мирзахан Нартдинов, Барий Талипов, из Ахтияла – Гильмиагзам Ахметшин. А сам Гилимхан Шамсетдинович научился играть на маленькой гармони Фаузи Ахмадиева. Потом купил баян, хромку. Ни один вечер, ни один «аулак ой» (посиделки в отсутствии старших) не проходили без его гармони.

Вступает в разговор и невестка Флюра, жена дяди Гилимхана:

– Раньше молодежь была более энергичной. С восходом солнца начинаешь работу, возвращаешься только с темнотой. Еще идешь на вторую смену, на зерноток, провеивать хлеб. Лишь бы терпели



*Г. Фазлыев на сцене. Март 1998 г.*

руки. Но в деревне никогда не стихали песни и мелодии. Даже на пути на зерноток успевали зайти в клуб, поплясать (это уже после войны). На ногах – лапти. На лугу проходили вечерние игры молодежи.

Гилимхан Фазлыев участвует почти во всех концертах и спектаклях, организованных при Истякском сельском Доме культуры. Комедию «Похищение девушки» поставили в районе четырнадцать раз, выступали даже на сцене государственного театра города Сарапула. Негде было яблоку упасть. После спектакля сарапульцы от всей души веселились под гармонь: плясали, танцевали, пели. Успех этих спектаклей, концертов во многом зависел от выступления гармониста дяди Гилимхана.

И сейчас Г. Фазлыев – участник многих праздников и различных мероприятий – на деревенской сцене, в школе, в детском саду. Только в День пожилых людей побывал в трех местах, выступал в составе мужского ансамбля, подарил столько радости, тем заслу-

жил благодарность. Вот так он всегда среди людей, вместе радуется с ними, разгоняет скуку и тоску. Не это ли служение народу? Кроме того, сколько зовут его на юбилеи, свадьбы, званые обеды, сабантуй, наконец. (А сам вот уже 25 лет не пьет и не курит.) Отказать или ждать упрашивания – не в его характере. Если уж попросят, то может и спеть.

– И сейчас гармонистов в деревне немало, но на сцену не затащишь, – говорит самодеятельный гармонист.

Флюра апа и дочь Иралия говорят, что ему стоит услышать новую хорошую мелодию по радио или телевизору, пока не научится играть, не остановишь. А с маленьким транзистором не расстается даже тогда, когда ухаживает за домашней животностью. Быстро сходится с людьми, обходителен, дружелюбен. Еще одна привычка: когда сядет за стол, хлеб нарежет красивыми ломтями. Это и понятно: по профессии Гилимхан Шамсутдинович – комбайнер, механизатор. Начал в 50-е годы, ушел на пенсию в 1989 году, но еще четыре сезона убирал хлеб на комбайне. Был и заведующим фермой, участвовал и в других работах. Не раз писала о нем районная газета. Да и сейчас не сидит дома, обслуживает отопительную систему здания правления колхоза. И не только. Сыновья Ильдар и Ирек были бессменными его помощниками. Сегодня Ильдар – механик УТТ, Ирек там же водитель.

Эти записи о Г. Ш. Фазлыеве, об односельчанине, который неустанно служит своей нации, народу, хочу завершить его любимой песней:

Я – колхоза бригадир,<br>Комбайнер и тракторист,<br>Если надо, и танкист,<br>На досуге – гармонист.

*«Янаульские зори», № 145 от 16 сентября 1995 г.*

# Талантың канатлы, иҗатың саваплы синең

Табигать нишләп үзенең балаларына тигез карамый торгандыр инде: берәүләргә бөтен һөнәрләрне, осталыкны, матурлыкны, бәхетне өеп бирә, икенчеләргә исә балкашыклап кына, чеметеп кенә өләшә. Раһип Мардислам улы Исламов табигатьнең яраткан баласы ул, аңа югарыда саналган сыйфатларны Ходай кызганмаган. Ул төп һөнәре буенча татар теле һәм әдәбияты укытучысы, шуңа өстәп җыр-музыка да укыта, оста биюче һәм баянчы, төрле музыка коралларында уйный, рәссам, балта остасы, шигырьләр дә яза, шулай ук үзешчән композитор да, артист та.

Раһип Мардислам улы татар һәм башкорт моңнары очрашкан җирдә, ямьле Агыйделкәйнең тыныч кына аккан урыныннан якында гына урнашкан Актаныш районының (Татарстан) Түбән Гәрәй авылында туа. Мәктәптә укыган елларында ук музыка, рәсем белән кызыксына, артист буласы килә аның. Такталачык урта мәктәбен тәмамлагач, Стәрлетамак мәдәният техникумында укып белемен ныгыта.

Билгеле, кара кашлы, кап-кара чәчле чибәр егет менә дигән артист та булыр иде, бәлки. Ләкин язмыш аны Истәк урта мәктәбенә алып килә. 1963-1974 еллар, ягъни 12 ел үткән гомер әзсез генә югалмый. Ул татар теле һәм әдәбияты, җыр-музыка дәресләре алып бара. Сыйныфтан тыш чаралар үткәрә, авыл сәхнәләрендә чыгышлар ясый. Мәктәпнең яшь укытучылар коллективы Раһип Мардислам улына ышаныч күрсәтә, аңа таянып, җыр-бию ансамбльләре, сәхнә әсәрләре оештыра. Ансамбль, үзешчән артистларының чыгышларын халык бик яратып каршы ала, район смотрларында призлы урыннарны яулыйлар.

Раһип Мардислам улы Истәк мәктәбендә эшләгәндә көйләр яза башлый, 1960 елларда ул Уфа шәһәрендә үткәрелгән баянчылар смотрында ике тапкыр лауреат исемен яулый.

Истәктә укыткан елларында Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Югары квалификацияле



*Р. Исламов эш урынында.*

һөнәрмәнгә әйләнә. Тагын да бик әһәмиятле хәл: бик тә унган, бик тә чибәр, тырыш, шунда рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән Әдисә Моталлап кызы белән танышып кавышалар. Алар бер кыз (Сөмбел рус теле һәм әдәбияты укытучысы, бер егет – Зөфәр – баянчы, укытучы) тәрбияләп үстерделәр. Ике ел Вәрәшбаш мәктәбендә директор булып эшләп алгач, 1977 елда Исламовлар гаиләсе Ямады авылына кайтып төпләнә. Яшь гаилә өй мәшәкатьләре генә түгел, укыту-тәрбия эшләренә дә чума. Урта мәктәптә музыка кабинетын җиһазлау Р. Исламовның төп эшенә әверелә.

Ул төрле шәһәрләрдән музыка кораллары, ноталар, уку әсбаплары жыя, вокал-инструменталь ансамбль төзи. Ансамбльнең беренче музыкантлары Ямады егетләре Әлфит Әхтәмов, Рим Закиров, Илһам Хәйдәршин, Салават Хужиннар булалар. Ул оештырган һәм өйрәткән баянчылар, тальянчылар, кубызчылар һәм халык инструменталь ансамбле район смотрларында беренче урынны яулый.

Унган укытучы укучылар өчен көйләр яза, аларны жырларга өйрәтә. Аның жырлары «Аманат», «Башкортстан укытучысы» журналларында һәм гәзитләрдә басыла, ул Башкортстан телевидениесенең «Җәйгор» программасында чыгыш ясый.

– Әдәбият дәресләрен тагын да сәнгатьлерәк итеп укыту өчен музыканың әһәмияте бик зур, – ди Раһип Мардислам улы.

– Хәзер мин класстан тыш эшләр өчен көйләрне блоклап язам. Менә, мәсәлән, көз яисә кышка багышланган кичәләрне жырсыз, музыкасыз үткәрсәң, эстетик тәрбияләүнең нәтижәлелегенә ирешеп булмас, ул көткән нәтижәне бирмәс иде. Минем төп бурычым – һәр бала, һәркем күнеленә нәфислек бүләк итү. Нәфислекне аңлаган кеше иманлы, тәүфыйклы булып яшәр, моның шулай булачагына иманым камил.

Шатландырып, кешеләрнең күнелләрен нурландырып яшә, Раһип дус, талантың канатлы, ижатың саваплы синең.

# Үрләр яулаганда

Йөгәмәш якларына барып чыккан һәр кешенең күз карашы үзеннән үзе иң элек Йөгәмәш-тауга төшә. Биек тә, матур да ул Йөгәмәш-тау! Итәгеннән алып түбәсенә кадәр кемдер аны бик нечкәләп һәм зәвык белән дөрес геометрик формада коеп куйган диярсең. Әйе, табигать оста рәссам да, скульптор да икән ул. Хайран калырлык!

Кайчан, ничек барлыкка килде икән бу тау? Их, беләсе иде шуның серләрен. Халык арасында йөргән легендалар аны тагын да серлерәк итә. Моннан күп еллар элек тау башында күл булган имеш. Бу күл шундый тирән булган, ди, хәтта ике дилбегә ялгап төшереп тә төбенә җиткерә алмаганнар. Күлнең кучкыл зәңгәр суында озак еллар пар үрдәк яшәгән. Ләкин көннәрнең берендә ниндидер аучы килеп, аларны атып алган. Өч көн, өч төн пешергәннәр үрдәкләрне, ләкин рәхимсез аучы үрдәк итеннән авыз итә алмаган. Ә күл үрдәкләрен сагынып кипкән, корыган, урынында чокыр гына уелып калган.

Әнә нинди гаҗәп күренешләр турында сөйли безгә легенда.

Тау башындагы вышкага менеп кара әле син. Тирә-яктагы күпме авыл аннан уч төбендәге кебек күренә. Әнә Иҗбулды авылы янындагы Кала-тау. Йөгәмәш-тау белән алар инде ничә гасыр бер-берсенә гашыйк булып карашып торалар сыман.

Халыкта сакланган легендаларны тыңлап әсирләнгән Йөгәмәш кызы Розаның шул тауларга мавыгып карамый калган көннәре булдымы икән? Һәр яшь йөрәк биеккә, югарыга үрмәләргә, үзен чолгап алган офыкны киңәйтергә омтылган шикелле, Роза да иптәшләре белән шул тауга күтәрелде, тирә-якны күзәтте, кып-кызыл җиләкләр җыйды, табигатьнең гүзәллегенә сокланып үсте.

Ә инде мәктәп еллары үтеп киткәч, сигезьеллык белем турында таныклык алган кызның күңелендә изге теләк өлгерде: укытучы булырга, кешеләргә табигать һәм галәм серләренә тирәнрәк төшенергә ярдәм итәргә, туган якларга, туган төяккә мәхәббәт тәрбияләргә! Һәм ул Бәләбәй педучилищесына юл тотты.

– Укытучы – иң изге, иң хөрмәтле профессия. Әтиең дә укытучы булган. Семьягызда ун бала арасыннан синең укытучы булуыңа әти-әниең дә, туганнарың да бик шат булырлар, – дип хупладылар аның теләген укытучылар.

...Роза Әхмәдишина менә унбер ел инде үзе теләп, яратып башлаган укытучы эшен алып бара. Башта өч ел Иске Уртавыл мәктәбендә укытты.

